# Язмышны җиңеп яшәгән язучы

Үткән гасырның соңгы дәверен өйрәнгән галимнәр танылган прозаик Газиз Кашаф-Үзиле исемен һич кенә дә читләп үтә алмаслардыр. Г. Кашаповның әдәбиятта үз йөзе, кабатланмас стиле, ул гына һәрьяклап күрсәтә алган тема — үзе хезмәт иткән чор совет армиясенең кырыс, вакыты белән аяусыз тормышын гадел һәм ихлас яктырту омтылышы бар иде. Алга китеп әйтәм: аны язучы итеп таныткан беренче зур әсәре дә, вафаты алдыннан гына тәмамлаган иң соңгы әсәре дә — армия тормышыннан алынып язылган әсәрләр.

*Бәйгеләрдә җиңеп чыккан кебек,*
*Ялларына ятып атымның,*
*Аяз көндә олы юлга чыгып,*
*Еллар кочагына атылдым.*

Баштагы иҗаты хакында Мөхәммәт Мәһдиев: "...Язучының тел-тасвир чараларында җылылык җитми.

Моның сәбәбе бар: яшьлеге формалашкан чорга туры килгән казарма, строй, наряд — рәхимсез кырыс устав таләпләре. Шулардан башка армия буламыни?" — дип язган иде.

Кырыслык, һәрнәрсәдә тәртипкә омтылу Газиз Кашаповның бар тормышы өчен хас сыйфат булса да, бөтен иҗатын болай тамгалап кую белән килешеп бетәсе килми. Чөнки аны әдәбиятка шигърияткә мәхәббәт алып килде. Аның шигырьләре тойгыларга бай, якты киерешле, оптимистик рухлы һәм кеше җанының олылыгын раслыйлар, табигать белән шәхеснең бербөтенлеген гаять кызыклы гомумиләштерүләр белән ачып бирәләр.

Газиз Кашапов (Газизҗан Салихҗан улы Кашапов) 1942 елның 21 августында Татарстан Республикасының Аксубай районы Яңа Үзи авылында туган. Әтисе Салихҗан сугышта һәлак була, әнисе Бану апа исә, кечкенә Газизҗанны әбисе кулында калдырып, авылдан китәргә мәҗбүр була. 1957 елда туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Иске Ибрай урта мәктәбенә укырга керә һәм 1960 елда өлгергәнлек аттестаты алганнан соң колхозда бухгалтер ярдәмчесе, тракторчы, клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендә армия сафларына алына. Әтисе офицер булганга күрәдер инде, Газизнең үзенең дә бик тә офицер шинелен киясе килә, һәм, форсат табып, инде өйләнгән, баласы булуга карамастан, хәрби училищега барып керә. Офицер тормышы Газиз Кашаповка күп нәрсә бирә. Ул аның бәхете дә, фаҗигасе дә. 1969 елда (кайбер истәлекләрдә 1968 елда) хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә аварияга эләгеп, каты җәрәхәтләнә, инде аякка бастым дигәндә янә бер фаҗига... Озак-озак госпитальләрдә яту һәм хәрби хезмәткә яраксыз дип табылу. Язучының, үзенчәләп әйтсәк, "гомернең утлы өлеше" тәмам, инде гомернең икенче — аны дөньяга таныткан газаплы өлеше башлана — калган гомерен язучы иҗат итеп һәм... яшәү өчен көрәшеп үткәрә.

1973 елда Г. Кашапов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә. Шушы ук елларда Әлмәт шәһәренә күчеп килә. "Хезмәт байрагы" газетасына эшкә урнаша. Беренче җитди проза әсәрен — "Сәмум җиле" повестен ул Әлмәттә яза, повесть 1976 елда "Казан утлары" журналында басылып чыга һәм укучылар аны җылы каршылый. Озак та үтми (1978), язучы Чаллы шәһәренә килә, КАМАЗ радиотапшырулар редакциясендә хәбәрче, "Социалистик Татарстан" газетасында үз хәбәрче булып эшли. 1983 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә. 1988—1989 елларда Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе итеп сайлана. Ул 1991 елның 30 августында безнең арабыздан китте, үзенең васыяте буенча туган авылына кайтарып җирләнде. Каберенә ташны дусты Тәлгать Нәҗмиев куйган...

Газиз Кашапов кыска гына иҗат гомерендә киң колачлы язучы, әдип булып җитеште. "Солдат иртә ир була", "Убырут", "Лачын кошка күкләр кадерле", "Җир җылысы", "Кыямәт бүлмәсе", "Елан агуы" повестьларын, "Язмышыңа ышан", Хәсән Туфанга багышланган "Киек каз юлы" романнарын укучылар яратып укыйлар. Күп санлы хикәяләре, актуаль проблемалар күтәргән публицистикасы, шигырьләре әдәби эшләнешләре ягыннан күңелне җәлеп итәрлек.

Кызганыч, шушындый бай мирас калдырган язучының иҗаты үзе вафатыннан соң нык-лап өйрәнелми, архивы да төрле урыннарга таралган. Зур өлеше Яңа Үзидәге музейда, бер өлеше Чаллыда — шәһәр музеенда һәм гаиләсендә саклана. "Мәйдан" журналының бу саны язучы иҗатын тәфсилләп барлауда беренче адым булыр, әдәбиятны өйрәнүче галимнәргә этәргеч бирер, Газиз Кашаповның якты образын күзалларга ярдәм итәр, дип уйлыйбыз.

**Фәкил САФИН.**



**Рәшит ХӘМӘДИЕВ,**
*Чаллы шәһәр хакиме*

# Һәрвакыт истә...

Язмыш мине күп кешеләр белән очраштырып тора. Алар арасында әдәбият-сәнгать өлкәсендә танылган шәхесләр дә аз түгел. Якташым Газиз Кашапов белән дә яшьтән үк таныш. Аның Аксубай район газетасында басылган беренче шигырьләре үзләренең ихласлыгы белән күңелгә хуш килде. Ул аерым бер үҗәтлек, тырышлык куеп иҗат итте, исеме татар әдәбиятында билгеле урын тота икән, аңа Газиз Кашапов гаять зур хезмәт нәтиҗәсендә иреште. Талант һәм тырышлык — иҗатның ике канаты шулар булырга тиештер.

Үзе зур әдип булып танылу алгач, әдәбиятны тирәнтен өйрәнгәч кенә, Газиз Кашапов татар әдәбиятының горурлыгы булган Хәсән ага Туфанның тормыш һәм иҗат биографиясен өйрәнә башлады. Башта ул Хәсән Туфан язмышын колачлаган "Җилләр улы" поэмасын язды, инде легендар әдипнең үткән сукмаклары буйлап меңнәрчә чакрым юл үткәч, Туфан утырган төрмә архивыннан аның "шәхси архивы"н эзләп табуга иреште, гаять бай фактик материал туплагач кына "Киек каз юлы" дигән зур роман язарга тотынды. Кызганыч, ул җыйган материалның бик азы гына романның беренче китабына керде. Калганнарын кем өйрәнер, кем дөньяга чыгарыр, әлеге сорау мине бик борчый. Бу уңайдан шунысын да искәртеп әйтү кирәк, Газиз Кашапов роман язу нияте белән чынлап йөри башлагач, аның белән ныклап аралашкан кайбер каләмдәшләре Туфанның әдәбияттагы урынын киметеп күрсәтергә тырышып мәкаләләр чыгардылар, белүемчә, аның үзенә дә шушындый эчтәлектәге хатлар язып, аның иҗади "накалын" сүндерергә, эздән чыгарырга омтылдылар. Ләкин Газиз Кашапов җил уңаена иман алыштырып яшәүче шәхес түгел иде, бирешмәде, чигенмәде, эшен дәвам иттерде. Әгәр вакытсыз үлем арабыздан алып китмәгән булса, Туфанның бөеклеген раслаган, шәхес буларак фаҗигасен күрсәткән роман яза алган булыр иде ул, һәм, ышанып әйтәм, аның әсәре татар әдәбиятының йөзек кашына әверелер иде...

Минзәлә, Зәй районнарын җитәкләгән вакытта якташ, язучы буларак, соңрак "Социалистик Татарстан" газетасының безнең төбәктәге үз хәбәрчесе буларак та миңа аның белән еш очрашырга туры килде. Райондагы эшләр торышы хакында объектив мәкаләләр язып, халык арасында ышаныч яулады. Вакыт табып, бергә сөйләшеп утырырга туры килсә, үзенең башыннан кичкәннәр хакында сөйли, хәтта минем белән, ышанычлы интәш һәм якташ итептер инде, иҗат һәм тормышына кагылышлы серләре белән дә уртаклаша иде. Аның тәкъдиме белән Чаллыда яшәп иҗат итүче язучылар, алар арасында Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин, Нәҗип Мәдияров еш булдылар, авыл хезмәтчәннәре янына килеп, әдәби очрашулар үткәрделәр. Тагын шунысын да әйтим, Газиз Кашапов минем эш кабинетыма бер үзе генә сирәк кергәндер, һәрвакыт янында бер каләмдәше булыр, шул дустына нинди дә булса ярдәм, булышлык оештырып йөреше булыр. Ул бик ярдәмчел кеше, күпләр аның бу әйбәт сыйфатыннан ныклап файдалана иделәр.

Тынгысыз җаны һәрчак аны каядыр әйди, ашкындыра иде. Йә ул Казанга күчеп китмәкче, йә Уфага тартыла, йә авылга кайтып йорт салам, шунда яшәп иҗат итәм дип ашкына. Болар хакында миннән дә киңәшләр сорый. Сәламәтлегенең мондый нагрузкаларны күтәрә алмаслыгын белгәнгә, ашыкмаска, сабырлык белән эш итү яхшырак буласын әйтә килдем. Күңелен бушатканнан соң ул тынычланып кала, борчулары басыла төшә, ул инде дөньядагы күп нәрсәләр хакында хәбәрдар гәптәшкә, үзенә тартып торучы кызыклы шәхескә әверелә.

Газиз Кашаповка алтмыш яшь тулган көннәрдә аның иҗатын, тормыш биографиясен барлап халыкка тәкъдим итү — матур эш. Әдип халык өчен иҗат итте, халык гаме белән янып яшәде, шушы тынгысызлык, җанын бимазалап торган кичерешләр аны безнең арабыздан иртә алып китте дә инде. Талантлы язучының иң зур бәхете шулдыр — үзе мәңгелек йортка күчсә дә, аның иҗаты яши, һаман да туган халкыбызга хезмәт итә. Мин аны һәрвакыт искә алып, сагынып яшим.

**Илһам ВӘЛИЕВ,**
*Аксубай районы хакимият башлыгы*



# Аксубай горурлыгы

Аксубай якларына килеп чыккан һәркемне күңелгә газиз Татарстанның күзләр күнеккән гүзәл манзарасы каршы ала, озатып кала. Безнең өчен гадәтидән дә гадәти инде бу хәлләр, шулай да кайсы ягы беләндер үзенчәлекле, үзенә һәрчак тартып торган серле яклар бу. Кешеләргә килсәк, алар да башка төбәкләрдә яшәүчеләр кебек үк: эш сөючән, булганның кадерен белеп, булмаганны булдырып, заманча яшәргә, көн итәргә омтылып яшиләр. Шулай да, бер үзенчәлекләре бар — сүзгә тапкырлар, әйтәсен кистереп әйтәләр, әмма буш сүз сөйләнеп йөрүчеләрдән түгел алар. Аксубай ягына килеп чыгучылар кырларда дулкынланып утырган мул иген кырларына сокланалар, аның меңьяшәр Шәрбән, борынгы "Хуҗалар тавы" кебек тарихи урыннарында йөреп, "Изгеләр чишмәсе" кебек җаннарга көч-дәрт бирүче салкын суларыннан авыз итеп үзләренә иҗади җегәр алалар. Район Татарстанның иң көньягында, биредә кышлар кырыс, җәй бернечә градуска эссерәк. Кайбер хуҗалыклар һәр гектардан 40—50 центнер ашлык җыеп алалар икән, моңа нинди хезмәт белән ирешелгәнен аңлатып торасы юк. Соңгы елларда терлекчелек тармагына да игътибар артты. Районның "Киса" совхозы, "Аксубай", "Нур", "Үсәр" "Чулпан" кумәк хуҗалыклары елдан ел яңа үрләр яулап, башкаларга матур үрнәк күрсәтәләр.

Аксубай, димәк, шифалы, көмештәй саф чишмә-инешләргә бай як, татар халкына менә дигән талант ияләрен биргән төбәк тә ул. Шушы табигатьнең илаһи почмагында Нәҗип Думави, Хәсән Туфан кебек бөек шагыйрьләрнең, Газиз Кашапов, Нәбирә Гыйматдинова кебек атаклы язучыларның, Сәет Хәмәдиев, Роза Туфитулова, Хөсәен Вәлиәхмәтов кебек тынгысыз журналистларның туул бер дә гаҗәп түгел. Халык үзенең талантлы улларын ярата, кадерли. Мин моны Хәсән Туфанның 100 еллыгын үткәреп йөргән көннәрдә янә бер мәртәбә күрдем. Район хакимиятенең ихлас булышлыгы белән Иске Кармәттә Туфанның музей-йортын сафка бастырдык, хәзер монда әдәбият сөючеләр бик еш сәфәр кылалар. Әле күптән түгел Чаллы шәһәр хакиме Рәшит Сәет улы Хәмәдиев шәһәр зыялыларын — язучылар, журналистлар, студентлар, мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре, укучы балалардан торган зур делегацияне Иске Кармәткә алып килде. Чаллы Язучылар оешмасы бу эштә башлап йөрүчеләрнең берсе иде. Шулай булмый мөмкин дә түгел, Чаллыда озак еллар икенче күренекле язучыбыз — Газиз Кашапов яшәде, иҗат итте, берара Чаллы язучыларының җитәкчесе дә булып торды.

Язучының туган авылы Яңа Үзидә музее эшләп килә. Музейны төзүдә җан атып йөргән барлык кешеләргә рәхмәт. Газиз Кашапов һәрвакыт якташларының эш-гамәлләре белән кызыксынып, бәйләнешне өзмичә, элемтәләрне даими яңартып яшәде. Бигрәк тә кешеләрнең табигатькә, бер-берсенә мөнәсәбәтләре хакында үзәккә үткәрерлек итеп әйтә белгән ул. Аның үз заманы өчен әйтелгән фикерләре бүген дә мөһим. Язучының кайсы гына әсәрен алма, аның туган ягына сыенуын, үз як кешеләреннән иҗат дәрте алуын аңлыйсың. "Сәмум җиле" повестенда Яңа Үзигә ямь биреп аккан Сөлчә елгасын — Төмчә, Аксубайны — Куксубай, Яңа Үзиен — Яңа Кизү дип кенә үзгәрткән дә, үзенең туган ягын, үзенең җанына якын кешеләрнең холыкларын, төс-кыяфәтләрен "кертеп кенә утырткан" әсәренә.

Аксубайлылар якташ язучыбызның тууына 60 яшь тулуны зурлап уздырырга җыена. Хәтергә Аяз Гыйләҗевның аның хакында әйткәннәре искә төшә: "Газиз нииндидер бер дәрәҗәдә язмышына хуҗа булырга тырышты... Буш сүз түгел бу. Безнең язучылар күргәннәре әзлектән, кичергәннәре сайлыктан җәфа чигә. Язучының иҗат биеклеген үзе кичерешләренә бирә алган бәянең гаделлеге дә билгели. Газиз үз чордашлары арасында иң бай тормыш кичергән шәхес", — дигән иде ул. Газиз Кашапов яшәүнең асылын аңлаган, туган ягыннан бетмәс-төкәнмәс илһам алып яшәгән туры сүзле, матур күңелле әдип иде. Чаллы шәһәр хакимияте оештырган "Мәйдан" журналының Газиз Кашаповка багышлап аерым сан чыгарырга алынуы хуплауга лаек. Аның иҗатын барлау, киләчәккә илтү — барыбызның да изге бурычы.

# Син Үзинең бер газизе идең...

Үзи авылы Казаннан бик ерак, Аксубайдан да ерак. Район үзәгенә кайтып төшкәч тә ул әле дөньяның икенче бер почмагындадыр кебек тоела. Бу авылда Газиз Кашапов туып үскән. Тиздән аңа 60 яшь тулыр иде... Мәһабәт гәүдәле, зәңгәр күзле язучыны күңелемнән генә авыл урамнарыннан йөртеп карыйм, юк, булмый, ул анда сыймый һәм, кош сыман, рәшә уйнаклаган офыкларга китеп югала. Шуңа күрәдер, каләмдәшнең Үзидә туып-үсүенә ышанып та бетеп булмый. Ә ул — Үзидән, Үзи бәгыреннән әдәбият дөньясына агып килгән чишмә. Мин аның белән бик аз аралаштым. Соңрак таныштык, әгәр Газиз абый бүген исән булса, без, мөгаен, иң якын якташ дусларга әйләнер идек. Чөнки ул минем рухыма тәңгәл кешеләрнең берсе, күңеле саф, гамәлләре изге иде... Ике мәртәбә очрашуыбыз хәтергә аеруча нык сеңгән. Бер төркем Казан язучылары Чаллыга барган идек, Камил Кәримов белән икебезне Газиз абый үз фатирына чакырды. (Елын төгәл генә хәтерләмим). Шунда безне бик тәмле тары өйрәсе белән сыйлады ул. Мин бүлмәдәге китапларның күплегенә шаккаткан идем. Газиз абыйның Хәсән Туфан турында китап язу өчен мәгълүматлар туплап йөргән көннәре иде бу. Шагыйрь эзләре буйлап, ул хәтта Уралдагы Лысьва шәһәренә дә барып чыккан иде. (Дусты Туфан Миңнуллин белән). "Карагыз әле, егетләр, миндә нинди зур табыш бар" дип, ул Камил белән миңа шагыйрьнең хатыны Луиза Салиаскарованың 14 яшьтә язган көндәлек дәфтәрен күрсәтте.

Икенче тапкыр күңелсезрәк урында күрештек без. Газиз абый Казан хастаханәсендә реанимация бүлегендә ята иде. Пыяла савытка тутырып мин аңа мүк җиләге китердем һәм карават янәшәсендәге тумбочка өстенә куеп калдырдым. Соңыннан, терелгәч, ул:

— Шул мүк җиләге мине коткарды, ахрысы, гәүдәне кымшатырга ярамый ич, үрелеп алам да авызга кабып суырам, үрелеп алам да... Рәхмәт сиңа, — диде. Бу хакта исемемне кертеп бер хикәясендә дә язган иде.

Нигәдер ул гомере өзеләсе соңгы елларда авылында йорт салып яшәргә хыялланды (Чаллы белән Үзи арасы да бик ерак). Һәм аның бу хыялы һаман барып чыкмады, шуңа ул бәргәләнә-өзгәләнә, күпмедер дәрәҗәдә сәламәтлегенә дә зыян сала иде бугай әле. Нишләп Үзи аны үзенә тартты икән? Язучының монда сагынырлык нәрсәсе бар иде соң? Газизҗан әтисе сугышта чакта туган, димәк, ата белән ул бер тапкыр  да очрашмаган. Әнисе өч яшендә калдырып, билгесез тарафларга китеп барган, ятим малайны әбисе Маһруй ялгызы гына үстергән. Җелегенә үткән ачлы-туклы балачак хатирәләре генә дә ир уртасы кешене Үзиеннән шактый ерагайтырга тиеш кебек иде. Бит Чаллыда тормышы мул һәм көйле иде. Туган җирен яратуы шулхәтле көчле иде микәнни? Мин моны аңлый алмадым, бу кайтуымда да җавап эзләдем — тапмадым. Хәер, без, язучы халкы, шәһәрдә яшәп, шәһәрдә картайсак та, авыл дип саташабыз. Сәер мәхәббәт бездә, сәер мәхәббәт...

Үзидә мине мәктәп директоры (шулай ук Газиз Кашапов исемендәге музей мөдире дә) Альбина Зартдинова көтеп тора иде инде.

— Бүген ничәсе, беләсеңме? — диде ул.

— 21 август,— дидем.

— Бүген Газиз абыйның туган көне бит.

Миңа бик уңайсыз булды. Газиз Кашаповның август аенда туганын беләм, әмма көнен төгәл генә хәтерләми идем. Ничек туры килүен күр син, ә! Алдан сөйләшеп куйган төсле, нәкъ аның туган көнендә, үз исемендәге музеенда хатирәләр яңартабыз икән. Әнә язучының яраткан укытучысы Рәшидә апа килде. Әнә ишектә туганнан туган абыйсы Ислам абый күренде.

**Рәшидә Мәхмүтова:**

1954—55 уку елында мин Үзи мәктәбенә математика укытучысы булып килдем. Укучылар белән бик тиз уртак тел таптым. Газизҗан бөтен эчке кичерешләрен дә минем белән уртаклаша иде. Аның иң беренче теләге — әтисе кебек офицер булу иде: Суворов училищесына укырга керергә дә теләде, ләкин анда яшьтән үк алалар икән.

Икенче хыялы язучы булу иде.

VII класста укыганда шигырьләр һәм пьесалар яза иде. Дәфтәр тутырып яза да миңа тикшерергә бирә. Мин, математика укытучысы, әлбәттә, грамматик хаталарны гына төзәтәм, әдәби юнәлеш бирә алмыйм. Ул: "Ничек язучы булырга?" — дип, "Татарстан яшьләре" газетасына мөрәҗәгать итте. Шуннан Г. Әпсәләмовның ачык хаты басылды.

Озакка сузылган каты авырулардан соң Газизҗан КДУның филология факультетына укырга керде, аны "5"ле билгеләренә генә тәмамлады. "Сәмум җиле" дигән әсәре аерым китап булып басылып чыккач, ирем белән без бик шатландык. "Рәхимҗан абый, Рәшидә апа! Сезнең олы хезмәтегезне зурлап, сәламәтлек һәм бәхетле көннәр теләп, шәкертегез Газизҗан", — дип, ул бер-бер артлы китапларын безгә дә бүләк итә иде.

Билгеле, Газизҗанга тормыш гел елмаеп кына тормады, хыялларына да ирешмәде ул. Барлык гомере аның эзләнеп үтте. Әнисен, туганнарын эзләде, Хәсән Туфан эзләре буйлап әллә кайларга барды. Кыска гына гомерендә бернichә кеше башкарырлык эшләр башкарды.

**Ислам Кашапов:**

Безнең Салих абый кадровый хезмәттән соң Мәскәүдә милиция хезмәтендә кала. Шунда Бану исемле кызга өйләнә. Җиңги Буа шәһәрендә туып-үсә. 1941 елда сугыш башлангач, Салих абый сугышка китә, ә җиңги Яңа Үзигә — кайнанасы, ягъни безнең әби янына кайта. 1942 елның августында Газизҗан энекәш дөньяга килә. Бану җиңги авыл Советы каршында акча җыю буенча агент булып эшли иде, бәхетсезлеккә каршы, эшендә шкафын ватып, 30 мең сумлык заемын урладылар. Шуннан соң ул, хәзер мине төрмәгә ябалар инде дип куркып, беркемгә дә бернәрсә дә әйтмичә юкка чыкты. Газизҗан башта әнисен юксынып бик елады, ләкин әбиебез аңа ятимлек түшәге күрсәтмәде. Ул елларда халык ач-ялангач иде, байтак кеше ачлыктан шешенеп үлде. Әбиебез оныгын бик яхшы тәрбияләде. Аның кәҗәсе бар иде, бәрәңге чәчә иде. Тырыш, уңган карчык иде. Малайга 6 яшьләр чамасы иде, бер көнне әнисе кайтып төште. Үзенең бертуган абыйсы белән. Җиңгинең исән-сау икәнен шунда гына белдек. Газизҗанны алып китмәкче икән болар. 13 яшендә энекәш үзе дә югалды. Ул абыйсын эзләп табып, әнисенең адресын сорамакчы булган, аны милиция Нурлаттан тотып авылга кайтарды. Шуннан соң ул икенче тапкыр чыгып китте, абыйсын эзләп кайтты.

Газизҗан яшьтән үк чая иде. Авылда 7 класс тәмамлады. Аннан Иске Ибрай урта мәктәбендә укуын дәвам итте. Ибрайдан туры безгә кайта иде. Минем улым Таһирны бик ярата иде. Таһир, әле сөйләшә белмәсә дә, абыйсын күргәч бик шатлана иде. Газизҗанга Ибрайда тракторда эшләү таныклыгы да бирделәр. Һәм ул төрле тракторларда эшләде. Әбиебез үлгәч, егет Фәһимә исемле кызга өйләнде. Армиягә киткәч, укып офицер булды, хатынын да үз янына алдырды. Ләкин авариягә эләккәч, аңа армия тормышыннан аерылырга туры килде. Югыйсә, Газизҗан хөкемгә тартылган солдатларны төзәтү командиры иде, ничәмә йөзләгән яшь егетне тәрбияләп частьларына озатты ул.

Шуннан алар гаиләсе белән Чиләбе шәһәрендә яшәделәр. Аннары фатирларын алмаштырып Әлмәткә күч236ендәр. Соңгы елларда Чаллы шәһәрендә яшәделәр.

Үзигә кайтса, ул бөтен туганнар белән дә күрешеп чыга иде. "Абый, хәлең ничек, авырмыйсыңмы?" — дип, һәрвакыт аркамнан кагып исәнләшер иде.

**Хәбибулла Һидиятуллин:**

Без Газиз энем белән көз көне бергәләп чөгендер җире сөрә идек. Берничә кызыклы вакыйга истә калган. Төнге сәгать 12 дә салам өеме өстендә йоклаучы Газизне уятырга мендем. Аны торгызып калдырдым да үзем төшеп киттем. Көтәм, көтәм, ул һаман төшми дә төшми. Шуннан: "Төш!" — дип бар көчемә кычкыруым булды, ул: "Ничек төшим, кадалып төшәм бит", — ди. Яңадан йоклап киткән дә төш күреп ята икән бу. Имеш, трактор чайкалып тора икән. Яңадан менеп, тотып алып төштем үзен. Шул ук көзне Аксубай сельхозтехникасына трактор ремонтларга бардык. Бер ай шунда эшләдек. Бервакыт тракторны майларга 2 фляга май алган идек, ярты савыт калды да, Газизҗан сорый: "Абый, монысын нишләтәбез?" — ди. Мин шаяртып: "Гусеница майлыйбыз", — дидем. Ул шундый беркатлы, тиз ышана торган, эчкерсез бала иде, күпмедер вакыт узгач: "Абый, гусеницаны кайчан майлыйбыз инде?" — ди. Армиягә киткәч тә ул миңа рәхмәт хатлары язды, минем турында "Хәбибулла Һидиятуллин — җир улы" дигән очерк бастырды. "Эшкә өйрәтүчем" дип мине бик олылый, хөрмәт итә иде ул. Баксаң, без икебез дә шушы туган җиргә береккән җир уллары булганбыз икән.

**Әхмәтзыя Моратшин:**

1962 ел иде. "Татарстан яшьләре" газитәсе кушуы буенча мин политукуларга багышлап материал туплаганда Үзигә бардым. Газизҗан ул вакытта колхозның комсомол оешмасы секретаре иде. Мотоциклга утырып бергәләп кырлар карадык. Соңрак ул армиягә китте. Аннан нык кына авырып кайткач, без аның белән бик еш очраша башладык. Туган авылына кайтышлый Газизҗан, Иске Кыязлыга тукталып, хәлне белеп чыга иде.

Мин, укытучы буларак, Газизҗанда берничә сыйфатны аерып куя идем. Беренчедән, ул үзенең укытучылары Рәшидә һәм Рәхимҗан Мәхмүтовларны якын күрә, нинди генә темага әңгәмә корсак та, аларны искә алмыйча калмый иде. "Менә, Рәшидә апаны күрергә кайтам әле. Менә, Рәшидә апаның юбилеена җыелабыз әле", — дип әйтеп куя иде. Икенчедән, ул туган авылын, авылдашларын ярата, бу мәхәббәт байтак әсәрләрендә чагылыш таба иде.

**Бибинур Хәмәтшина** (классташы):

...Газиз тирән кичерешләр, зур хыяллар белән яшәде, күпне белергә, күпне күрергә һәм шуларны кәгазьгә төшерергә ашыкты. Мәктәп елларыннан ук, әйтерсең, ул язучы булырга әзерләнгән.

Менә 5—6 нчы класс укучысы Газизҗан Г. Әпсәләмов хатларын иптәшләренә укый. Ул да түгел, шагыйрь Илдар Юзеевка хат юллый.

...Соңгы 8 елда Газиз безгә еш килеп йөрде. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар. Беренчедән, ирем Рифкать белән уртак тел таптылар, дуслаштылар. Икенчедән, ул Хәсән Туфан турында роман язу өчен шактый гына материаллар туплады. Кайбер хатларын саклаган идек, музеена тапшырабыз.

*Әссәламегаләйкем, Рифкать абый, Бибинур!*

*...Мин Казанга бик зур мәкалә язып барган идем. Кире алып кайттым, өстәмә яздым. Ләкин аны бастырып чыгару минем өскә бик күп бәла-каза китерәчәк инде. Шуңа карамастан, мин тәвәккәлләргә булдым. Билгеле, теге кешеләрнең каршылыгын җиңеп, бастырып чыгарып булса... Булмавы да бик ихтимал. Безнең бит анда... плюрализм түгел, плюнаризм...*

*...Романымны машинкада басып яталар, яртысы булды. Тик... Казанга бу баруымда аның да язмышына кагылышлы усал җилләр барлыгын белеп кайттым. Аны дөньяга чыгармау кампаниясе башланган да икән инде. Мәрхүм булса да, Хәсән агабыз һаман да фронтның алгы сафында әле ул. Аңа теш кайраучылар, аны күрмәскә тырышучылар, акны кара диюче, "кара кан"га батырырга тырышучылар бик күп, күп шул...*

*Уйладым-уйладым да, йорт салу ниятеннән әллә туктаргамы, дигән фикергә килә башладым әле. Аның урынына бу яклардагы берәр авылдан гына йорт сатып алырга булыр, ахрысы. Чөнки Минзәләдән дә, районнан да, Тукай районыннан да тәкъдимнәр бар инде. Шуларның берсе бигрәкләр дә ошый. Ул "Ижминводы" янындагы бер авылда...*

*Теге Лариса апа вакыйгалары турындагы хикәя өчен Гомәр белән Луиза миңа шалтыратып, әйтмәгәннәрен кал-*

*дырмадылар... Дуслык бетте. Шул араларда судка чакыртабыз диделәр әле...*

*Шундый хәлләр безнең.*

*Сезгә борчуларсыз гына, имин, сәламәт тормыш теләп калабыз.*

*Газизҗан.*
*4 февраль, 1991 ел.*
*Чаллыяр.*

**Гамирә Мингатина** (Г. Кашаповның каршы як күршесе):

Маһруй әби белән Газизҗан яшәгән йорт, кечкенә генә булса да, бик матур, чиста, ишегалдында ямь-яшел чирәм үсә иде. Шул йомшак чирәм өсләрендә уйнап үсте инде яланаяклы күршем Газизҗан. Ул үзенең әсәрләрендә: "Мин кечкенә малай вакытта бик усал, шук идем", — дип язса да, мин аның усал чагын хәтерләмим. Әбисен бик ярата, "әбием" генә дип эндәшә иде. Урамга чабып чыгып: "Безнең Бану әни кайта диләр, каршы алырга барам әле", — дип сөйләгәннәре хәтердә.

Маһруй әби турында күңелдә бары тик якты истәлекләр генә саклыйм. Ул бик рәхимле карчык иде. Кул арбасы тартып тамак туйдырганда да Газизҗанга язучы булырлык тәрбия бирде. Гомерем буе шул әбигә сокланып яшәдем.

**Рәхимҗан Мәхмүтов:**

Газиз Кашаповны 1956 елдан бирле беләм. Рәшидә үз укучылары турында яратып, аз гына уңышларына да сөенеп, тәртип бозсалар — борчылып сөйли иде миңа. 1957 елда Аксубай район гәзитендә эшли башладым. 1982 елда Газиз Үзигә очрашуга Эдуард Касыймов белән Нәҗип Мәдияровны да алып кайтты. Аларны минем белән таныштырганда: "Минем беренче остазым", — диде. Мин сәерсенеп карап торгач: "Минем беренче язмаларымны гәзитәдә бастыручы абый", — дип өстәде. Гомеренең соңгы көннәренә хәтле без аның белән очрашып тордык. Ул хатлар да яза иде. Беренче хатны Кызыл Арваттан, госпитальдә ятканда язды. Шул вакытта, дөнья белән бәхилләшкәндәй: "Абый, балаларымны аякка бастыруда Фәһимәгә булыш", — дип үтенгән иде. Фәһимәгә минем ярдәмем кирәк булмады, Газизнең тимердәй нык ихтыяр көче авыруны җиңәргә ярдәм итте. Аның Шәрифҗамал апалардан (хатынының әнисе): "Абый, бүген бер генә тапкыр ял итеп сезгә килеп җиттем", — дип, балаларча шатланып ишектән килеп керүе һаман да күз алдымда әле.

Үзем дә авариягә очрап, Лениногорск хастаханәсендә ятканда, Газиз яныма килә һәм: "Абый, сер бирмә, мин нинди хәлдә идем, терелдем бит, син дә аякка басарга тиеш", — дип көч бирә иде.

**Юныс Ситдыйков** (күршесе һәм яшьлек дусты):

Безнең балачак һәм яшьлек авыр елларга туры килде. Газизҗан шигырендә әйтелгәнчә:

Без малайлар идек. Елый-елый
Әтиләрне өйгә күпме дәштек...

Газиз, өч яшеннән әнисез калып, әбисе кулында үсте. Өскә кияргә кием, авыз тутырып ашарга ипи булмаса да, ул үзен кимсетмәде. Башак җыеп, эскерт төпләрендә калган бөртекләрне себереп, шулар белән тамак туйдырдык без. Беләкләргә бераз көч туплангач, ат көтүе көтә башладык. Учак янына утырып, киләчәккә матур планнар кора идек. Ул елларда безгә эшләгәнебез өчен хезмәт көне язалар иде. Җәй буе сарык бәрәннәренә яшел себерке әзерли идек. Печән вакыты җитсә, үгезләр җигеп печән ташырга кушалар иде. Комбайннан бөртек ташыган чаклар да бүгенгедәй күз алдында тора. Кичләрен клубка да чыгасы килә безнең. Өстеңә кияргә киемең юк, дип тормый бит ул яшьлек. Кино карыйсы, кыз кисәкләре белән дә очрашасы бар. Эштән кайткач, шул ук киемеңнең тузанын кагып киясең дә китәсең клубка. Элек "Тарзан" дигән фильм күрсәтәләр иде. Керәсе килә шуңа, акча юк, хезмәт көненә икмәк белән генә түлиләр.

Без алай төшеп калган малайлар түгел идек. Иске клубның бер башында идән астына керә торган тишек бар иде. Без шуннан гына кереп кино карый идек. Бервакыт безне күргәннәр дә тишекне агач бүкән белән каплап куйганнар. Сәхнәгә чыга торган юл да бикләнгән. Кино карыйсы урынга төне буе идән астында утырдык Газиз белән.

Күрше хәрби булырга хыяллана иде. Без бишмәтләребезгә погоннар тагып, сугыш уеннары уйный, походларга йөри

идек. Бакча башы без казыган чокыр-окоплар белән чуарланып бетә иде.

**Альбина Зартдинова:**

Без ирем Әхмәдулла белән читтән торып институтта укыганда, Х. Туфан яшәгән урамдагы бер фатирда — Риза абый Бадыгиннарда туктала идек. Авылдаш язучыбыз Газиз Кашапов та аларга килеп йөри иде. Шул вакытта Газиз абый белән бик нык дуслашып киттек. "Сәмум җиле" әсәрен, кульязма хәлендә, иң беренче ул миңа укытты. Башым авырта иде, "Син нигә күңелсез, сеңлем?" — ди Газиз абый. Сәбәбен әйткәч, кесәсеннән кечкенә генә төймә-дару чыгарып бирде. Үзенең дә сәламәтлеге начар булган икән бит...

Ул туган авылы Үзине бик ярата иде. Фамилиясе янәшәсенә "Үзиле" дип тә өстәде. Авылда йорт салып, шунда кайтып-кайтып иҗат итү иде исәбе, тик бу нияте барып чыкмады. Гомере иртә өзелде аның, 49 яшьтә әле кеше яши генә башлый, ә Газиз абый китте дә барды. Без авылдашыбызны онытмаска тиеш идек, бер көнне Рәшит Гафуров белән утырдык та "музей төзергә кирәк" дигән карар чыгардык. Икебезнең карарны. Музей буласы ике бүлмәдә элек коммуналь хезмәт күрсәтәләр иде, районга йөри-йөри без аны бушаттырдык. Колхоздан машина сорап Чаллыга киттек. Газиз абыйның хатыны безгә мәрхүмнең әйберләрен биреп җибәрде. Әлбәттә, музей авырлык белән оешты, яшермим, без аны Рәшит белән үз хисабыбыздан булдырдык. Ә ишегалдында һәйкәл утыртыр өчен йорт саен кереп авыл халкыннан акча җыйдык. Гаиләсенең дә, туганнарының да өлеше керде. Язучының дусты, Саба районы гәзитәсе баш редакторы Тәлгать Нәҗмиев аның каберенә, үз акчасына ясатып, таш кайтарып куйды. Менә тугры дус нинди була икән ул!

Аллага шөкер, музеебыз ун ел эшли. Биредән халык өзелгәне юк.

### Соңгы сүз

Язучыда сизгерлек шулкадәр көчле була ки, ул үзенең үлемен дә алдан күреп, алдан ук сүзен әйтеп куя. Мисаллар байтак. 1989 елның салкын гыйнвар аенда Газиз Кашапов та шигырь юлларына салып васыять яза:

Мине белгәннәргә бер үтенеч,
Соңгы сүзем итеп белегез:
Җаным чыккач, мине Бикчабарның
Тау башына илтеп күмегез.

Бикчабар — Яңа Үзинең югары як зираты. Васыять язылып ике ел үткәч, әдип мәңгегә Үзиенә кайта. Мәңгегә... Кайчандыр авылында йорт салып яшәргә хыялланган якташ каләмдәшкә Бикчабарында берни дә кирәк түгел инде...

**Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА.**

## Яшәвенең мәгънәсе иҗат иде

Газиз Кашапов белән якыннанрак танышып китүем 1979—1980 елларга туры килә. Чаллыга килеп, бер йортта яши башлагач, еш кына аларга кунакка керә идем.

Беренче керүемдә үк мин аның фатирында китаплар күп булуга игътибар иттем. Китаплар шкафы хәтта коридорда да тора иде. Ә инде Газизнең үз бүлмәсендә бөтен өч як стена буйлап киштәләргә китаплар шыплап тутырылган. Анда барлык татар һәм рус әдәбияты язучыларының әсәрләре генә түгел, ә бөтендөнья әдәбияты классикларының томнары тигез итеп тезеп куелган иде. Әйе, ул вакытта инде Газизнең үз алдына бер бөек максат куеп, җаны-тәне белән иҗатка бирелеп, үзе яшәгән җәмгыятьне һәм заманны тарихта сәнгать чаралары белән тасвирлап калдырырга омтылып яшәгән чагы иде. Инде шушы 1980 елларда ук ул үз тормышының төп мәгънәсен бары әдәби иҗатта гына күрә башлаган иде.

Ул елларда Газиз "Социалистик Татарстан" газетасының Чаллы төбәге буенча үз хәбәрчесе булып эшли иде.

Икенче бер керүемдә ул үзенең язу өстәле каршындагы стенага нечкә генә тал чыбыкларыннан үрелгән бер пар чабата элеп куйган иде. Һәм ул шунда: "Татар баеса, чабатасын түргә элә, дип әйтәләр. Ә мин чабатаны түргә элеп куйгач, ничек була икән ул, баеп була микән — шуны белергә элдем", — дип шаяртты.

Мин Газизнең иҗат белән янып яшәвенә соклана идем. "Язмышыңа ышан" романы өстендә ничек җан атып эшләвен беләм. Бервакыт, 1984 елның кыш көнендә мин Газизне Алабугада, Чаллыга борыла торган юл чатында очраттым. Мин, дәресләрне бетереп, Алабугадан Чаллыга кайтырга "попутный" машинага кул күтәреп торам. Ә Газиз Чаллыдан килгән машинадан килеп төште. Газиз миңа "Казан утлары" журналының әле язылып бетмәгән "Язмышыңа ышан" әсәрен бастырырга ризалык биргәнлеге һәм шул әсәрне тиз көндә язып төгәлләү өчен Алабуганың "Прикамнефть" профилакториена бер айлык путевка алганлыгы, шунда китеп баруы турында сөйләде.

Минем көндәлекләрдә Газиз турындагы мәгълүматлар аеруча 1981—85 елларда күп язылган. Менә аларның кайберләре:

"1981 ел, 18 сентябрь. Кич белән сәгать 6 да "Энергетик" мәдәният сараенда "Ләйсән" әдәби берләшмәсенең отчет-сайлау җыелышы булды. Берләшмә җитәкчесе итеп яңадан Газиз Кашаповны сайлап куйдык".

"1981 ел, 12 октябрь. Газиз Кашапов Чаллы Язучылар оешмасы пропаганда бүлегенә эшкә урнашкан".

"1982 ел, 28 февраль. Газиз янына барып, бераз сөйләшеп кайттым".

"1982 ел, 6 март. Кичке сәгать 6 да Алабуга пединститутының Чаллы филиалында студентларның язучылар белән очрашуы булды. Аны оештыручы мин идем. Очрашуны Разил Вәлиев алып барды. Язучылардан Эдуард Касыймов, Газиз Кашапов, Нәҗип Мәдияров, Хәниф Хөснуллин, Рәшит Бәшәров килгән иде".

"1982 ел, 9 апрель. "Энергетик" мәдәният сараенда җыр кичәсе булды. Концерттан Газиз Кашапов һәм аның хатыны Фәһимә белән бергә кайттык."

Мин бу көнне яхшы хәтерлим. Ул кичәдә, шыгрым тулы залда, кайсыдыр бер ир-ат артист (кем икәнлеге хәтеремдә калмаган) Газиз Кашаповның "Әтием, бәгырем" җырын башкарды. Шул чакта Газиз: "Әниләр турында җырны күпләр язалар. Ә әтиләр турында җыр юк. Баланы тәрбияләүдә әтиләрнең дә роле зур бит. Хәзерге заманда әтисез генә бала тәрбияләп кара! Әниләр алар баланы иркәләргә генә торалар. Ә әтиләр баланы билгеле бер рамкаларда тотып торалар. Менә шуңа мин әтиләр турында җыр яздым", — дип горурланып сөйләгән иде.

Газиз Кашаповка мин тагын шуның өчен дә рәхмәтле: 1970—1980 елларда Чаллы шәһәр хакимияте тарафыннан КАМАЗ төзелешендә һәм шәһәрнең иҗтимагый тормышында актив катнашкан, үзенең иҗаты белән КАМАЗ тормышына билгеле бер өлеш керткән иҗат әһелләренә "КАМАЗ төзелеше ударнигы" дигән мактаулы исем бирелә иде. Газиз Кашапов Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы секретаре булып эшләгән вакытта тагын бер төркем яшь каләм әгъзаларыннан "КАМАЗ төзелеше ударнигы" исемен бирергә лаеклы шәхесләрнең исемлеге төзелде. Газиз Кашапов әлеге исемлеккә мине дә керткән.

Газиз минем хәтеремдә, гомумән, кешеләр хәтерендә яхшы исеме белән, кешеләрне дулкынландыра — елата да, сөендерә дә торган әдәби әсәрләре белән калды. Үзең үлгәннән соң да хөрмәт ителү — ул һәрбер кеше хыяллана торган биеклек һәм бөеклек бит!

**Әнвәр ШӘРИПОВ,**
*филология фәннәре докторы,*
*Чаллы педагогия институтының татар филологиясе кафедрасы мөдире.*
*25 июль, 2002 ел.*

# Аксубай каһарманы

*Нигә соң бергә чакларның*
*Белмибез кадерләрен...*

*Халык җырыннан.*

Газиз Кашаф-Үзиле тормышның бар матур-ямьсез, гадәти кырыс-кырын, хозур-илһамлы көннәрен-төннәрен, айларын-елларын кичерә-уза гомер итте.

Хәрби хезмәттә имгәнгәч, Мәскәүдәге үзәк шифаханәдә ул чактагы Совет Армиясенең баш хирургы Вишневский (заманында Казанның атаклы табибы булган А.В.Вишневскийның улы) Газизнең теткәләнгән гәүдәсен тәүлекләр буе ярып-җыеп яңадан тегә.

Сызланулы айлар, интегүле озын-озак еллар буена шифаханәләрнең төрлесендә офицер егет үлем белән тарткалаша. Хәле бераз җиңеләеп, зиһене аязып алган чакларында балачакта әбисе өйрәткән теләк-догаларын, кайдандыр, үз күңеле, үз җаны чоңгылларыннан ук моңга-җырга охшап калыккан аһәңле авазларны, челтәр-челтәр сүз тезмәләрен пышылдый башлый ул. Газаплар чытырманында шагыйрь туа!..

Әлегә гомере киселмәгән булган, шөкер. Аллаһ, табигать биргән куәтле-кодрәтле йөрәге, сабый чагыннан ук саф һавада, садә авылының урам-тыкрыкларында бәбкә үләннәре, песи борчаклары өстендә, болын-тугайларда, урман-суларда сут-мәдәт туплап өлгергән, яшьли "кара эш" белән тыгызланып-ныгып үскән хәзинәле организмы (әлбәттә, ихлас табибларның, әбиләр генә саклап килә алган халык медицинасының шифалы-сихәтле ярдәме белән) Газиз Кашапов атлы адәм баласын үлем тырнагыннан шактый елларга йолып кала.

Без Чаллыда очрашып яшәгәндә, илнең-көннең җәмәгатьчелеге күреп белгән Газиз Кашапов инде "елаган үгез сыман" таза-көр, бик елгыр-җиңел сөякле, һәр хәрәкәткә, аваз-өнгә кичекмәстән үз гамен белдерергә әзер торучы, урта буйлы, тыгыз бәдәнле, горур-тәкәббер рәвешле, сыек зәңгәр күзле, кара-коңгырт чәчле-кашлы, үстереп җибәргән чакларында куе сакал-мыеклы, кырыс-карлыкканрак, ләкин моңын җуймаган тавышлы, нинди шарт-ситуация туса — шуңа табигый бирелеп, йә нурланып-балкып китүчән, йә бар рәнҗү-үпкә, ачулану-нәфрәтләнү хисләрен яшерә алмыйча тузынып, дуамалланып, ямьсезләнеп, кыргыйланып китүчән дөньяви бер катлаулы шәхес иде. И-и, Ходаем, гадәти бер баланә да шундый бай, катлаулы-каршылыклы табигать-холык, михнәтләр-бәхетләр, сөенеч-көенечләр өләшә-өләшә, әлегәчә без төшенеп җитә алмаган илаһи гамәлләр, хөкемнәр кыласың бугай шул...

Әйткәнебезчә, без белгәндә-күргәндә, ул бик тә җегәрле, гайрәтле, аеруча (гаскәрилектән сеңгән) һәр адымда тәртип-режим-дисциплина таләп итүчән һәм бик тә шаушулы оештыру эшләренә һәвәс ир-егет иде.

Ул кешеләр белән бик тиз аралашып, уртак тел, дус-иш таба белә, ярдәмчел, киңәшкә атлыгып тора, әлбәттә, үз бәясен-мәнфәгатен дә онытмаучан заман вәкиле иде.

Ул җитәкләгән ике елда, чынлап та, Чаллы-Чулман төбәгендәге язучылар оешмасында башкорт, чуаш, мари, урыс әдәбиятчылары белән бергәләп, дуслашып шактый игелекле эшләр эшләнде, иҗади көчләребезнең халык белән аралашу манзарасы, һәртөрле чаралары киңәеп-баеп китте.

Өенә барып кергәндә дә Газиз, халык әйткәнчә, күтәреп алырга әзер, ихлас шат, ачык-көләч каршылый, үзе үк килүченең өстен-башын чишендереп мәш килә, өлгерелгыр гына кухнясында уралып ала да, килүчене табынга чакыра, һичшиксез ниндидер берәр затлы эчемлек тә китереп куя, әлбәттә, кунакка зурысын, ә үзенә — (кунак тарсынмасын өчен, мөгаен) бәләкәй генә рюмка алып, шул "уймак"ка да бер-ике тамчы эчемлек тамызып, тотып куйгандай була. Ихлас кыстый, шаяра-көлә, берәр мәзәк сөйләп ала, ышанган кешесе булсаң — эч серләрен дә яшерми бүлешә, язу-иҗат хакында сүз чыкса, калын-буаз папкаларга биләүләгән материалларын күрсәтергә ашыга, ният-өметләрен илһамланып, дулкынланып бәян итә.

Аның безнең заман өчен бер "атрибуты" сәеррәк иде: Газизнең китап-кәгазь баштин ашкан эш бүлмәсендә, зур тәрәзә рамында ап-ак пар киндерәле, бик тә пөхтә, зәвыклы-тыгыз үрелгән пар чабата эленеп торыр иде. Кергәч тә шул бер кием чабатага күзең төшә, тәннәрең җирсеп китә, күңелең моңсу-әрнүле дә, якты сөенечле дә самими хисләр өермәсе бөтерелеп керә, өзек-өзек уйларың үткән заманнарны, үзеңнең дә бала-үсмер чакларыңның чабаталы, агач башмаклы, киндер ыштанлы ярлы-ырку елларын урап кайта...

Шул моңлы хатирәләр, бәргәләнгән уйлар-хисләр дулкынында утә саклык, гаять кадер-хөрмәт белән ул пар чабатаны кат-кат сыйпаштырып-иркәләп каравыңны күргәч, Газиз моңсу-оялчан гына елмаеп беравык басып тора. Аннары ниндидер гаебеннән акланган үсмер малай тавышы белән:

— Татар түрә булса, чабатасын түргә элә, дия күрмә инде, малай. Түрә булуларны Ходай безгә насыйп итмәгәндер инде. Бу чабаталарны... күргән нужаларыбызны онытмасыннар өчен тотам, — дип сөйләнә торган иде.

Әйткәнемчә, тормышның бар кытлыгын, камчысын-чыбыркысын, бар "сәмум җиле"н күреп-кичереп үскән Газиз Кашапов, шөкер, гомеренең соңгы дистә елларында, әлбәттә, үз тырышлыгы, үз әрсезлеге белән шактый хәлле, ризыклы, мәртәбәле көннәргә ирешә. Ул үзе, әйткәнемчә, табигате-холкы белән саран-карун кеше түгел иде. Ләкин үзе тапкан мал-мөлкәтнең бәрәкәтен-кадерен белүче, шуңа шөкерана кылучы, үз тапканын бер дә юкка-барга исраф итмәс тәртипле, сак ир-егет иде.

Янә әйткәнебезчә, күрер күзгә ул никадәр мәһабәт-таза, гайрәтле-гаярь, нурлы-сөйкемле, шаян-шат булмасын, еш кына "йөгәннән ычкына", көнче-гайбәтчеләр ялганына да ышанып дуамал ярсый, бәргәләнә, катгый сүзне, бигрәк тә кырыс-усалрак әйтелгән сүзне бер дә өнәми, күтәрә алмый, буена сеңдерә алмый — тәмам туарылып китүчән хәтәр зат иде. Ихтимал, мөмкинлекләр-шартлар булып та, театр белгечләре әйткәнчә, фактурасы булса да, безнең Газиз Кашаповны җитәкче-административ эшләргә ары күтәрергә бигүк теләмәвебез, "әйдә, лучше тынычрак шартларда яшәсен, күбрәк әдәби иҗат белән мәшгуль булсын", дигән тактика тотуыбыз — әнә шул гамәлләр аркасында булды. Чөнки, нишләтәсең, ул гаскәри хезмәттә алган яраларыннан (никадәр дәваланса да) мантый алмаган, гомерлек фаталь чирле булып калган икән шул, Газиз Кашапов дигән асыл ир-егет инде физик-психологик биртелгән шәхес иде, әлеге дуамаллык, әлеге гариплек — бу аның бәхетсезлеге, хәят өчен дә үкенечле фаҗигасе иде...

Ә язучы-прозаик, шагыйрь һәм журналист-публицист буларак Газиз Кашаф-Үзиле... (гомерләрнең мизгелләр агымы гына булуына кат-кат сискәнеп куясың да уфтанасың). Әле менә кайчан гына, әйтерсең, кул сузымыдай якын елларда гына, күренекле әдибебез Әдип ага Маликов Газизнең беренче көлтә шигырьләрен хуш күреп, аңа матбугатта хәер-фатыйха биргән иде. Әле кайчан гына мөхтәрәм шәхес, чып-чын каләм батыры Габдрахман ага Әпсәләмов Газизнең беренче "Сәмум җиле" дигән повестена шатланып, аның татар әдәбиятында хәрби тематиканы дәвам итәчәгенә өметләрен баглаган иде, бу юнәлештә аңа үзенең ихлас киңәшләрен биреп, аның химаячесе-яклаучысы булган иде...

Өлкәннәрнең бу ышанычын, өметләрен аклар өчен Газиз бик тырышып иҗат итте, күп укыды, өйрәнде, үз тормышының офыкларын һәрдаим киңәйтергә атлыгып яшәде. Исәпле-санаулы еллар эчендә үк Газиз Кашапов бер-бер артлы "Еллар тыныч иде", "Гомернең утлы өлеше", "Вөҗдан хәтере", "Язмышыңа ышан" исемле әсәрләрен газета-журнал битләрендә һәм мөстәкыйль китаплар итеп тә укучыларга тәкъдим итәргә өлгерә алды. Бу әсәрләргә заман укучысының мөнәсәбәте, хөкем-бәяләре, әлбәттә, төрлечә булды. Берәүләр аларны мавыгып, яратып укыдылар, үз фикерләрен язып газета-журналларга яки әдипнең үзенә үк хат-хәбәрләрен җибәрделәр, икенче берәүләр — ары укырга теләмичә "күтәреп бәрделәр", авторны ясалма-ялганда гаепләделәр. Нишләтәсең, һәркемнең үз зәвыгы, әдәби сәнгатькә үз таләбе шул...

Күп, бихисап күп талантларның аңына-җанына сеңдерелгән коммунистик-кызыл идеология, әйткәнебезчә, реаль тормыш нужа-рәхәтләрен, иншалла, җитәрлек татыганбелгән Газиз Кашаповка да үз мөстәкыйль фикерен әйтергә, үз җанын сыкраткан хәл-

әхвәлләрне ак кәгазь битләрендә реаль чагылдырып халыкка җиткерергә мөмкинлек-җай бирмәде шул. Әсәрләрендәге купшы-кызыл идеяләр, ясалма-ялган ситуация-вакыйгалар, манекен персонажлар, автор теләгәнчә генә әйтелгән-сөйләнгән, әмма халыкчан булмаган монологлар, диалоглар..."социалистик реализм әдәбиятының" гомуми фаҗигасе, әлбәттә, Газиз Кашаповның да бәхетсезлеге, бәласе булды... Ләкин акыл, холкы-табигате белән сизгер-зирәк, тиз төшенүчән Газиз иман-ышанычларның яңарасын, пакьләнәсен, безнең илдә дә заманнарның үзгәрәсен, шул нәүбәттә, әдәбият-сәнгатьнең дә, шәхсән шәхесләрнең дә тоташ унитар идеологиядән котылырга тырышып бәргәләнүен тоемлый башлаган иде инде.

" — Малай, мәчет төзелешенә дип, өч йөз сум акча биргән идем. Шоны гаепкә санап авылга да кайтып сүләгәннәр. Коммунист башы белән, янәсе!..."

Инде җаннарны биздергән коммунистик "актуальлек"тән — конъюнктурадан бигрәк, ихлас реаль образ тудырырга ниятләп, Газиз үз якташы, олуг шәхес һәм илаһи талант иясе Хәсән ага Туфан турында эпик поэма һәм роман язарга бик тырышып йөрде.

— Малай, сөйлә әле, Хәсән аганы сөргеннән ничек каршыладыгыз?

— Малай, сөйлә әле, университетта аның белән ничек беренче тапкыр шулкадәр зур очрашу уздыра алдыгыз? Гел аңа багышлап "Әдәби сүз" газетасын чыгаргансыз, Хәсән аганың зур портретын студент Нурмөхәммәт Хисамов ясаган диләр, дөресме? Ул чакта бит әле Хәсән аганың рәсми реабилитациясе дә булмаган икән... Малай, Хәсән ага трибунага чыккач, кем белән кочаклашып елады, Әхмәт Фәйзи беләнме, Мөхәммәт Садри беләнме?

— Малай, сөйлә әле, сабан туйларында ул ничегрәк утыра иде? Батырлар көрәшкәндә ниндирәк сүзләр әйтә иде?..

Газиз Кашаф-Үзиле бик күп шигырьләр дә язды. Язганнарын көндәлек матбугатта бастыра да белде, җаен тапты. Әлбәттә, бик чуар һәм төрлесе-төрле әдәби-эстетик дәрәҗәдәге тезмәләр алар. Игътибарлы-сак берәр мөхәррир табылганда, аларны барлап-сайлап, укучыларга тыйнак бер җыентык тәкъдим итәргә мөмкин.

" — Яшисе килүне әйткән дә юк инде, сөйләшәсе, фикер уртаклашасы, хәл-әхвәл сорашасы, телләрне кашыйсы килә башлады..." ("Кыямәт булмәсе" хикәясеннән.) — "Кыямәт бүлмәсендә бары тик бер җан иясе, әлегә йөрәге тибә торган бер бәндә — мин генә ятам. Хәер, бәлки әле туар көннең берсендә мин бу үзе иркен, ләкин искиткеч кысан бүлмәдән үз аякларым белән атлап якты дөньяга чыгып та китәрмен. Өметсез шайтан, диләр бит безнең халыкта".

— Малай, бу безнең шәһәрнең культура фонды дигән нәрсә барып чыкмадымыни? Юкса, мин инде аның уставын да Казаннан алып кайтып биргән идем. Үземнең дә җиң сызганып шул тирәдә эшләп йөрергә исәп юк түгел иде... Ярар, "Мирас"ның зур бер бүлеген оештырып җибәреп, яхшы эшләгәнсез. Хәерле сәгатьтә булсын икән дә бит, бер тиен акчасыз, телефонсыз, машинасыз килеш, белмим, ничекләр генә итеп ул оешманы яшәтә алырсың икән? Казаннарның буш вәгъдәләренә ышанып планнарыңны корма, аларның күбесендә иман да юк, оят та юк. Алар безне провинциягә саныйлар да, давай, бездән тегене-моны теләнергә тотыналар. Куйганнары бар диярсең. Янәсе, безнең язганнарны чыгарырга булышалар. Бар, булышырлар, киресенчә, бездән көнләшеп, туксан тугыз киртә куярга маташалар. Безгә, һәрвакыт үзебезгә көрәшеп, штурмлап йөрергә туры килә. Ярар, бу хакта син миннән шәбрәк беләсең ләбаса. Минем, дус итеп, исеңә төшерүем генә инде...

Үзем яңа повесть белән җенләнәм әле. "Елан агуы" дип атадым үзен. Укып чыгарсың да, фикер-киңәшләреңне әйтерсең, яме, малай...

Ходай гомерен биргән булса, Газиз Кашапов та берничә эволюция кичерә алыр иде, үз аңындагы-җанындагы хәзинәне, шәт, төрле жанрларда, ракурсларда укучыларына, халыкка җиткерә алыр иде. Нишләтәсең, адәм баласының гомере, мал-мөлкәте үз ихтыяҗ-ниятләреннән генә тормый икән шул. Һәр шәхеснең үз тәкъдире, үз язмышы, канат кагынган кыялары, егылган упкыннары... — болар барысы да Алла — табигать кодрәтендә икән бит...

**Фаяз ДУНАЙ.**

# Утыз ел бергә гомер иттек...

**Язучының язмышы гадел вә дөрес яктыртылырга, бәяләнергә тиеш. Шул максатны күздә тотып, мин күренекле язучының хатыны — Фәһимә апа Кашаповага мөрәҗәгать иттем. Һәм менә шушы сөйләшү нәтиҗәсендә туган язманы сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәбез.**

— Без Газизҗан белән бер авылда үсеп, бергә укып, бер чишмә сулары эчеп үстек. Беренче күрешүебез сигез-тугыз яшьләрдә булгандыр. Әнием мине туганыбыз Шәйдулла бабайларны кунакка чакырырга җибәрде, ә аларның күршесе Салихҗан абыйларның казлары бик тә күп, ә ата казлары бик усал иде. Мин шул казлар яныннан ничек үтәргә дә белми басып торганда, каршы йорттан бер малай йөгереп чыкты да, миңа: "Нәрсә, әллә куркасыңмы? Хәзер мин аларны таяк белән куам!" — диде.

Ул әтисенең апаларына яңа чалбар котлатырга менгән булган икән. Менә шулай беренче тапкыр очраштык. Ә икенче очрашуыбыз ул егылып, аягын авырттыргач, әбисе аны кечкенә арбага утыртып, минем әнием янына алып килгәндә булды. Минем әнием авыруларга ярдәм итә ала торган иде. Аягын утыртканда бик елады һәм мин аны кызганып, әнинең кунакларга саклап тоткан кәнфитләрен чыгарып бирдем. Күрше урам малае булып чыкты. Шунысы хәтердә уелып калган: алтынчы сыйныфта укыганда, экзамен вакытында, ул иптәш малае белән бергәләшеп бәхет эзләргә чыгып киткән иде бит әле. Дөрес, бер атнадан соң тотып кайтардылар үзләрен...

Шуңа күрә алтынчы сыйныфта икенче елга утырып калды ул. Һәм алтынчы-җиденче сыйныфларны без бер класста бетердек. Сигезенче-тугызынчы-унынчы сыйныфларны үзебездән егерме-егерме биш чакрым ераклыктагы Иске Ибрай авылы урта мәктәбенә йөреп укыдык. Укыган вакытларда без туганнарча бер-беребезгә ярдәм итешеп йөрдек. Үзидән булган биш—алты бала һәр атнаны авылга кайта идек (мунча керергә һәм атналык азык алып килергә) — таш яуса да кайтырга кирәк. Газизҗан бик үзсүзле, үпкәләүчән вә хурланучан булды — бу инде ятимлек билгесе, әлбәттә. Әтисе яуда һәлак булган, ә әнисен сугыш вакытындагы түрәләр Газизҗанга дүрт яшь кенә булганда авылдан качып китәргә мәҗбүр иткәннәр...

Аның әнисе бик матур була, страховой агент булып эшли. Ул районнан кайтканда, аның каршысына юлбасарлар чыгып, заемнарын талап алалар. Ул заемнарга әнисе авыл кешеләреннән җыеп алган акчаны түләгән булган, шуңа күрә төрмәгә утыртуларыннан куркып, тиз арада иренең әнисендә баласын калдырып, төнлә авылдан качып чыгып китә. (Әни сөйләгән истәлекләрдән)... Шулай итеп, Газизҗан ятим кала. Дөрес, әбисе үз улына пенсияне чагыштырмача күп ала иде, чөнки Газизҗанның әтисе сугышка офицер булып китә һәм батырларча һәлак була.

Газизҗан бала чактан ук язучы һәм офицер булырга хыялланды. Кайсысы көчлерәк булгандыр инде? Авылда укыган вакытта ук инде төрле әсәрләрне пьесаларга әйләндереп, безне репетицияларга калдырып, үзәккә үтеп бетте (дәрестән соңга калып кайткач, әниләрдән эләгә бит). Ә Иске Ибрайда укыган вакытта күрше авылларга да барып, концертлар һәм сәхнә әсәрләрен уйнап йөрдек. Боларның барысын да Газизҗан үзе җитәкләде, үзе оештырды. Әйе, оештыру сәләте көчле иде анда. Мәктәптә укуны тәмамлагач, без авылда калдык. Дөрес, Газизҗан Казанга барып, институтка керергә экзаменнар биреп йөрде, ләкин конкурстан үтә алмады. Шуннан соң Чиләбегә китеп, туганнары янына эшкә урнашкан иде, әмма авылда әбисе ялгыз булганга күрә, кире кайтты. Ул елны авылда җәй буе колхозда эшләдек. Мин аның икетуган сеңлесе Гөлсинә белән бергә машинада йөк төяүче булып йөрдем. Шул вакытта без якынаеп киттек бугай. Аның сөйләү, ә минем исә тыңлау сәләте бар иде. Шулай итеп, төнге сменаларда гел бергә йөри идек. Бөтен серләрен, авырлыкларын миңа сөйләп, эчен

бушата торган иде ул. Газизҗан бик җор телле матур егет булды, кызларның да күңелләренә үтеп керә ала, ышандыра белә иде. Без аның белән яшь вакытта ук бер-беребезгә тартылып яшәдек, ләкин мәхәббәт, ярату турында бер дә сөйләшми идек. Ул шуны белә, аңлый иде: әгәр дә башка кызларга сөйләгән сүзләрне миңа да әйтсә, мин аңардан читләшәчәкмен... Башка кызлардан буш вакытында мине дә озаткалый иде. Авылда бит күп эшләрне күмәкләшеп эшлисең. Мин бакча эшләрендә аңа булышсам, ул миңа чөгендер бушатышырга Нурлатка бара иде. Кайвакыт абыем янына мотоцикл ремонтлашырга килә һәм ремонт беткәч, абый мотоциклында урам әйләнергә ярата иде. Әбисе карт булганга күрә, аны армиягә үз яшьтәшләре белән бергә алмадылар — шуңа бик гарьләнеп йөрде ул...

1962 елда (яңа елдан соң) без өйләнешергә сөйләштек. Безнең сөйләшкәнне сеңлесе Гөлсинә әнисенә әйткән икән. Шулай итеп, бу сүз минем әнигә дә барып җиткән. Бер ай буе әни мине икетуган абыйларга саклаттырып йөрде. Әнинең мине бер дә аңа кияүгә бирәсе килмәде... Әмма Газизҗанның әбисе февраль башында үлеп китте һәм мин аңа 12 февраль төнне качып чыктым. Туебызны Газизҗанның икетуган Ислам абыйларында уздырдык.

Үзидә ул тракторист, завклуб эшләрен алып барды. Ә мин колхоз идарәсендә бухгалтериядә эшли идем. Шулай тыныч кына яшәп тә киттек. Озак та үтмәде, 1962 елның октябрендә армиягә повестка килде, нәкъ минем декретка чыккан көннәрдә. Бик үтенде инде армиягә җибәрүемне теләп. Шуңа күрә каршы да килмәдем. Берүзем өч тәрәзәле өйдә утырып калдым. Бер ел хезмәт иткәч, аны училищега җибәрделәр, ә ике елдан соң Төркестан хәрби округына Кызыл Арват шәһәренә хезмәткә направление алып кайтып та төште. Әмма мин аның белән китмәдем. Ул офицер, матур формада, үзен бик горур тота, ә мин — гади авыл хатыны... Армиядә вакытта элек йөргән кызы Зәлирә белән хат язышканнарын да ишеткән идем инде. Тик мин аңа ни өчен бармаганымның төп сәбәбен аңлатып, ачуланышып тормадым. "Бар, урнаш, ә квартира алгач, мин дә яныңа барырмын", — дип кире җибәрдем. Ә инде үзе авылдан киткәч, барын да аңлатып хат җибәрдем. Ләкин язмыштан узмыш юк диләр бит: ике ай буе һәркөн хат язып, телеграммалар җибәреп, военкоматка командирларыннан мине озатып җибәрүне сорап үтенечләр килгәч, абый мине үгетләп китәргә мәҗбүр итте: "Баланы ятим итмә!" — диеп. Шулай итеп, 1965 елда Төрекмәнстанга китеп бардым. Русча да әйбәт белмәгән авыл хатынына офицер хатыны булу бик авыр булды. Анда бик эссе, суны машина белән генә китерәләр иде. Кичтән юып калдырган савыт-сабалар иртән торганчы соры комга баткан була торган иде. Эш юк, бер зарплатага яшибез. Квартирада солдат караватларыннан башка берни дә юк. Шулай итеп, хәрбиләрчә яшәп киттек. 1966 елда кызыбыз Резидә туды, икенчесе дә кыз булды. "Малай тапканчы бала тудырасың!" — дип наказ бирде Газизҗан.

1968 елда хәрби частьларны өйрәнүләргә җибәрделәр һәм шунда бик каты ком бураннары башланды, өч-дүрт көн дәвамында. Шуннан Газизҗанны аңсыз хәлендә госпитальгә алып кайттылар. Мин инде өченче балага авырлы идем. Аллаһы Тәгалә кешегә сабырлык бирсә дә бирә икән: ул вакытларым исемә төшсә, хәзер дә исләрем китә! Чи ит янмый шул, түзеп була икән... "Адәм баласы шатлыкка кына түзә алмый, ә кайгыга түзә", дигән мәкальне шунда гына аңладым. Өч ай госпитальдә ятып чыкты, шуннан азрак уңайланган иде, эшкә чыкты. Мин инде соңгы көннәремне декретта йөри идем. 1969 елның мартында Гамил туды. Шул шатлыктан иптәшләре белән бик нык бәйрәм иткәннәр. Ике-өч көн буе. Һәм шуннан Газизгә бик нык приступ булып, аны яңадан госпитальгә салдылар. Больницадан улым белән икебезне елый-елый әнием килеп алды. (Әни ул көннәрдә Чорджауга сеңелләренә кунакка килгән иде, шуннан бала туган вакытка инде безгә дә килеп җитте.)

Газизҗан күпме көтеп алган малаен үзе каршылый да алмады... Менә шунда башланды инде тормышның әчесе. Ярый әле әнием, Аллаһының рәхмәте яусын, урыны җәннәттә булсын, безне ташламады, гел акчалата ярдәм итеп торды.

1970 елның январенда Газизҗанны Кустанайга күчерделәр, эссе җир аңа ярамый диеп. Ләкин анда да хезмәт итә алмады. Бер көн эшкә чыкса, ике-өч көн урында ята

иде. Алма-Атада госпитальдә ике ай дәвалангач, аны Ленинградка хәрби госпитальгә җибәрделәр. Анда айдан артык яткач, хезмәткә яраклы түгел дип, икенче группа инвалидлык биреп кайтардылар. Ул Кустанайда безнең яшәүләрне мин дошманыма да теләмим. Кәгазьгә язсаң, йөрәк әрнүләрем кәгазьләрне яндырыр иде...

Чиләбедә туганнар бар дигәч, анда күчеп киттек. Өч бала, туксан сум пенсия, авыру ир... Ләкин туганнарының ярдәме безгә тәтемәде. Рәхмәт яусын тагын әниемә. Үзем эшкә кердем, балаларны садикка урнаштырдык. Газизҗанга көненә өчәр тапкыр "скорый" чакырабыз. Чиләбе госпиталендәге профессор, ул инде үлә дигәч, әниемнең Мәскәүдәге танышлары аша Газизҗанны Мәскәүгә алып киттем.

Мәскәүнең Бурденко исемендәге нейрохирургия институтына урнаштырдым. Әгәр аны бер вакытта да ачуландырмасагыз, аның көенә, аның өчен генә яшәргә үзегездә көч таба алсагыз гына бу операцияне ясыйбыз, чөнки тормышта конфликтлар күп булса, ул акылын югалтыр, диделәр.

Мин үз сүземдә тордым... Газизҗан үзе дә бик түзде инде авыртуларына, врачлар әйткәнне тыңлады, эчүен-тартуын ташлады, тормыш өчен ныклап көрәш башлады. Әни май аеның үләннәрен җыйдырып (рәхмәт киленебез Нәфисә апага, ул җыя иде), җиде капчык киптереп куйган иде. Шулар белән көнаралаш мунчада яткырабыз. Барганда үзе бара, ә кайтканда абыйсы — Ислам абый күтәреп кайта. Һәр җәйдә шулай итеп әни дәвалады: Газизҗан акрын-акрын аякка басты. Аякка басса да, аның баш авыртулары, күзән җыерулар һәм какшаган нервлары гомерлеккә калды... Чиләбедән Казанга күчеп китәр өчен төрле вариантлар эзли башладык. Озакламый Казан университетына читтән торып укырга керде. Шул вакыттагы шатлыгын күрсәгез иде сез! Тик Казанга кайтып булмады, ә 1974 елда Әлмәткә кайтып урнаштык. Әлмәттә ул "Сәмум җиле" повестен яза башлады. Шул кечкенә генә повестьны да ун мәртәбә күчереп, яңартып язды. Иренмәде. Әмма Әлмәтне нигәдер яратмады ул. 1977 елда безнең дүртенче бала Дамир туды. Газизҗанның яраткан малае. Олылары үскәндә, авыру сәбәпле, аларның барлыкларын да белмәгән вакытлары күп булды шул. Балаларны тәрбияләү, ашатуэчертү, киендерү, укуларын карау — барысы да минем өстә иде.

Мин аңа уку һәм язу өчен бөтен мөмкинлекләрне дә бирдем. Аллага шөкер, Ходай Тәгалә минем язмышымны шулай язгандыр да. 1977 елның октябрендә без Чаллыга күчтек.

Язучы хатыны булу да җиңел түгел шул, бер мин генә түгел инде андый халәттә. Барлык язучыларның хатыннарына һәм балаларына Аллаһы Тәгалә олы сабырлык бирсен! Мин китаплар укырга бик ярата идем. Чын тормыш дип, елый-елый укый торган идем. Газизнең китабы басылып чыккач, бер-ике ел берни дә укый алмадым. Иптәшләре белән утырганда көлә торган иде: "Минем карчыгым, мин китап чыгаргач, бөтенләй китаплар укымый башлады", — дип. Язучыларның башларында уйлап чыгарылган хыялый тормыш икән ул.

Дөрес, аларның төп фактлары тормыштан алынган, ләкин язучылыкта — ул күптөрле тормышларны берләштерү икән. Газизнең барлык әсәрләре дә, шигырьләре дә минем күңел аша үткән. Иртән торыр иде дә: "Кара әле, карчык, син эштә вакытта мин ниләр яздым!" — дип, укый башлар иде. Беренче шигырьләрен: "Карчык, моны бит сиңа атап яздым", — дип әйтер иде, гәрчә ул шигырьләрне соңыннан башка хатын-кызларга да шулай дип әйтәчәгенә күңелем белән инансам да: "Әйе шул, булдыргансың, бигрәк матур язгансың", — дип, рәхмәт әйтеп, үбеп ала идем. "Матурлар"ны бик ярата иде шул. Шагыйрьләр барысы да шундый инде. Шуңа күрә дә күбесе аерылыша... Мин, гомерләр уза төшкәч, үзеннән дә сораганым булды: "Нигә без аерылышмадык?" — диеп. Көлә иде. "Әй, карчык, мине синең кебек беркем дә карамаячак, кадерләмәячәк бит, аларның үзләрен кадерлисе булачак, ә минем аңа көчем җитмәячәк"...

Дин кайткач, Газиз әнием белән күп сөйләшә-аңлаша башлады. Әниемә рәхмәте зур иде аның. "Әби булмаса, мин бу дөньяда яшәмәгән дә булыр идем", — диеп, дусларына да әйтә торган иде.

Иҗат кешесе язмышы белән үк үзенең "бәхетенә" дучар була инде ул. Язучы булырга аңа Аяз абыйдан да күбрәк ярдәм итүче булмагандыр, мөгаен. Бездә кунганда

да, Язучылар йортында эшләгәндә дә төннәр буе сөйләшеп чыгалар иде. Дөрес, Аяз абый аны бер вакытта да мактамады, башта Газиз хәтта бик ачуланып, үпкәләп тә йөрде. Соңыннан инде аңлаштылар. Мөхәммәт абый һәм Туфан абый белән дә аралары бик әйбәт булды. Газиз болай үзе эчкерсез кеше, әмма ни әйткәнен бик уйлап тормый иде шул. Каты телле булды, кеше хәтерен сакламый сөйләшә иде. Үзеннән ярдәм сорап мөрәҗәгать итсәләр, бик теләп, ихлас күңеленнән ярдәм күрсәтергә тырыша, ә инде ярдәм итә дә алса, балаларча куана-шатлана иде. Без утыз ел бергә гомер иттек. Шул вакыт дәверендә бездә кемнәр генә булмады да, кемнәр генә яшәмәде!.. Классташларымы, яшьлек дусларымы... Барысын да ачык йөз белән каршы ала идек. Әфганстандагы сугыш елларында татар егетләрен яклап газеталарга язды, телевидениедән сөйләде, дәүләт җитәкчеләренең үз балаларын ул якларга җибәрмәве, хәтта аларның армияга да алынмаулары турында язып чыкты. Шуның өчен күпме янаулар булды аңа. Балаларны да куркытып бетерделәр, үзенең дә күпме саулыгын бетерде. Татар мәктәпләренең ябылуына да бик кайгыра иде.

Үзебез матур гына итеп дүрт бала үстердек. Дөрес, тормыш гел ал да гөл генә булып тормады. Төрлесен үткәрергә туры килде... Монда инде минем дә гаебем булгандыр. Балалар кечкенә вакытта аралашулар җиңелрәк иде. Алар төпле уйлый белмиләр иде әле. Гомер буена: "Шауламагыз, телевизор озак карамагыз! Әтиегезне интектермәгез! Әтиегез авырый! Әтиегез яза..." — дигән сүзләрне еш ишетеп үсәргә туры килде аларга. Ә балалар үсеп җитеп, үзләренең теләкләрен белдерә башлагач, Газиз аптырашта калды: "Ничек инде мин теләгәнне алар аңламаска тиеш? Мин бит аларның атасы, мин начарлык теләмим!" — диеп, үзен-үзе тынгысызлады. Безнең "ярар" сүзләренә өйрәнеп җиткән иде шул. Күпме еллар буе өйдә аңа каршы килүче булмады. Гамил унны бетереп, Куйбышевка авиационныйга укырга киткәч, бер ел аның белән сөйләшмәде. (Газизнең аны Казанга укырга җибәрәсе килгән иде.) Соңгы елларда кызлар белән дә конфликт булып алды. Балык башыннан чери диләр: төптән уйлаганда, балаларның "миһербансыз" булуларына ата-ана гына гаепле. Мин дә бәлки гел уңай якка гына сыпырып торып арыганмындыр...

Аллага шөкер, балаларыбыз акыллы булып, тәртипле үстеләр. Олы кызыбыз Архангельскида укытучы булып эшли. Эшендә дә, тормышында да ихтирам итәләр. Икенчесе — Резидәбез матур гына кыз үстерә, сатучы булып эшли. (Укытучыларга хезмәт хакы түләмәгән елларда мәктәптән китте). Гамил — инде ике бала атасы. Ул шәхси предприятиедә финанс эшләрен җитәкли. Бәләкәй улыбыз Дамир шофер булып эшли. Бүгенге көндә, Аллага шөкер, кеше көлдереп, берсе дә эчеп, төннәр буе сугышып, кеше талап йөрмиләр. Аллаһы Тәгаләгә мин иксез-чиксез шөкермен.

Аллага шөкер, Газизҗанны үзе теләгәнчә, авылга алып кайтып җирләдек. Дуслары Мансур белән Якубка мин бик рәхмәтлемен. Алар башлап йөрделәр. Язучылар оешмасы һәм каләмдәшләре аны соңгы юлына Чаллыдан бик матур итеп озаттылар. Барча авыл халкы да саубуллашырга килде. Район, колхоз җитәкчеләренә, бигрәк тә хәзерге мәктәп директоры Альбинага һәм үземнең икетуган Рәхимҗан абыйга мин күп рәхмәтлемен. Шул елны ук Газизҗанның музеен ачарга да хәзерлек башланды, ә инде 50 яшьлек юбилеена музей ачылды да.

Шуннан соң без җәмгыять өчен онытылдык. Бары тик Газизнең дусты, Саба газетасының редакторы Тәлгать Нәҗмиев кына исәнлекләрне белешеп торды.

*Шушы, берничә сәгатькә сузылган әңгәмәбезнең ахырында мин Фәһимә апага үзем өчен дә бик мөһим булган сорау бирдем:*

*— Газизҗан исән булса, бүген ничек яшәр иде икән?*

*— Хәзерге вакытта Газиз исән булса, ул үз теләге белән дөньядан китәр иде инде. Спонсорлар эзләп китап чыгара алмас иде ул. Үзе өчен йөрергә дә, сорарга да бик хурланыр иде. Эшмәкәрлек аның табигатенә сыя алмаслык һөнәр...*

*Әңгәмәбезне тәмамлаганда, Фәһимә апа "Мәйдан" редакциясенә үзенең ихлас теләкләрен дә белдерде:*

*Бу журналны чыгарып, миллəтебез иминлеге өчен үзен аямыйча хезмəт иткəн шəхеслəрнең данын халкыбызга танытү, исемен мəңгелəштерү юлында йөргəн кешелəрне Аллаһы Тəгалə үз ярдəменнəн ташламасын, юллары уң булсын...*

*Әңгəмəдəш — Мансур САФИН.*

# Тынгысызлык

Әйе, 2002 елның 21 августында аңа 60 яшь тулган булыр иде. Ул моннан ун ел элек ярты гасырлык юбилеен да бик көткəн иде. 50 яшенə бер елдан да азрак калгач, ягъни, 49 тулуга, дөньяны, гаилəсен, туганнарын, дусларын, чəчəккə бөреленгəн иҗатын калдырып китеп барды Газизҗан. Язмыштан узмыш юк, дилəр. Шулай булса да ир уртасы кешенең, олы талант иясенең йөрəге тибүдəн мəңгегə туктавына ышанасы килми. Аның оптимистик рухта языла торган, яшəүгə, тормышка мəдхия җырлаган шигырьлəренə, хикəялəренə, повестьларына, романнарына рəхимсез үлем вакытсыз нокта куярга карар кылды. Үлем — котылгысыз, табигый. Аның шулай икəнен Газизҗан да дөрес аңлый иде. Әмма ул сəгатьнең кайчан сугасын белмəде, болары инде, өлкəннəр əйтмешли, бер Алланың үзенə генə мəгълүм булды.

...1991 елның 30 августы көнне авыр хəбəр килде. Яр Чаллыга ашыктым. Дүрт бүлмəле фатирының залында дустым йокымсыраган шикелле генə күзен бөтенлəйгə йомган. Чиста йөз (ул җан бирер алдыннан гына кырынып-юынган була), пөхтə чəчлəре...

Эш бүлмəсенə үттем. Ул 20 августта, шифаханəгə барыр алдыннан, күңеле белəн сизенгəн кебек, "Туган көнемə — 21 августка" исемле шигырен тəмамлап калдырган икəн...

Әйе, Газиз Кашапов өчен урман гына түгел, бөтен җиһан тынып калды. Кем уйлаган, дөнья белəн бəхиллəшү дəвалану гимнастикасы ясаганда булыр дип... Йөрəк өчен авыр заманада яшибез шул.

Газизҗан Аксубай районының Яңа Үзи авылында туа. Кечкенəдəн əти-əнисез калып, үзенең əбисе тəрбиясендə үсə. Туган авылында җидееллык, Иске Ибрайда урта мəктəп тəмамлагач, ике ел колхозда бухгалтер ярдəмчесе, аннары тракторчы һəм клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендə Совет Армиясе сафларына алынып, башта курсант, соңыннан гаскəри частьта механик булып хезмəт итə, Благовещенск (Амур өлкəсе) шəһəрендə хəрби училище тəмамлый. 1969 елда сугышчан вазыйфаларны үтəгəн чакта фаҗигадан алган җəрəхəтлəрдəн совет офицеры авырып китеп, бик озак госпитальлəрдə дəвалана, ə инде 1971 елда хəрби хезмəттəн бөтенлəй китəргə мəҗбүр була.

Безне Казан дəүлəт университеты дуслаштырды. 1973 елда бергə татар теле һəм əдəбияты бүлегенə читтəн торып укырга кердек. Соңыннан гаилəлəр белəн аралаштык, туганлаштык диярлек.

Газиз Кашапов язучы, шагыйрь генə түгел, көчле публицист та иде. Ул Әлмəт шəһəрендə чыга торган "Хезмəт байрагы" газетасы һəм КАМАЗ радиотапшырулар редакциялəрендə əдəби хезмəткəр, "Социалистик Татарстан" газетасының Түбəн Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үз хəбəрчесе булды. Аннары язучыларның Яр Чаллы оешмасын җитəклəде. Гомумəн, Газизҗан журналистиканы чын күңелдəн ярату. Вафатына өч ел калгач, ул Татарстан язучылары съездында татар публицистикасы турында ялкынлы отчет ясады һəм шул мөнбəрдəн төшүгə аңа көчле инфаркт булды. Шифаханəдə озак кына дəваланып чыкканнан соң, бер роман, ике повесть бастырып чыгарды, иҗат эшен бөтен көченə дəвам итте. Бигрəк тə якташы, танылган Хəсəн Туфанга багышланган "Киек каз юлы" дип исемлəнгəн роман өчен бик күп материал туплады. Г. Кашапов Туфан эзлəре буйлап күп йөрде, шагыйрь эшлəгəн Пермь өлкə-

сендәге Лысьва шәһәрендә мемориаль такта куюны һәм аны тантаналы төстә ачтыруны драматург Туфан абый Миңнуллин белән бергәләп оештырдылар. Аннары Газизҗан Туфан утырган төрмәгә барып, аның шәхси делосын күтәрттерде, шуның кесәсеннән "халык дошманы"ның өч рәсеменең берсен (алай алдан һәм ян яктан фотога төшәргә язмасын — Т.Н.) алып кайтты, Хәсән ага сөргендә булган Новосибирск өлкәсендәге авылны эзләп табып, аны белгән кешеләр белән очрашты, шагыйрь яшәгән землянка урынында төн кунды... Әмма Г. Кашапов бу романның бер кисәген генә тәмамлый алды. Ул "Киек каз юлы" дигән исем белән үзе үлгәннән соң гына басылып чыкты. Шунысы кызганыч, романның иң кызыклы икенче кисәге автор күңелендә китте. Бу хакта Татарстанның халык язучысы Аяз ага Гыйләҗев юкка гына болай дип язмагандыр: "Белүемчә, Газиз Кашаф-Үзиле гомеренең соңгы сулышына кадәр якташы Хәсән Туфанның гыйбрәтле язмышын роман битләрендә күрергә тырышып иҗат итте. Бу әсәр Хәсән Туфанга һәйкәл буласы иде... Ул аның үзенә дә һәйкәл булыр дип кем уйлаган? Авыр туфрагың җиңел булсын, Газиз!"

Халкыбызның иң яраткан язучысы, университет буенча остазыбыз Мөхәммәт абзый Мәһдиев та аның турында түбәндәге юлларны кәгазь битенә төшереп калдырды: "Газиз бик чиста күңелле егет иде. Чиста күңеллелек — язучы өчен иң кирәкле сыйфат. Вөҗдан дигән төшенчәне Газиз бик зурдан бәяли иде һәм ул үзенең кыска гомерен вөҗданын бик нык саклаган көе узды. Шуңадыр инде, үзе исән чакта дөнья күргән китабына исемне дә ул "Вөҗдан газабы" дип куйды..." ("Татарстан яшьләре", 11 август, 1992 ел). 1991 ел башында ул Ташкент якларында булып, элек туган төбәкләрендә яшәгән Сираҗетдин мулланың көндәлеген табып алып кайткач, тагын бер романлык материал бар, дип шатланып сөйләгән иде...

Газиз Кашапов "Сәмум җиле" дип исемләнгән автобиографик повесть белән үзен прозаик итеп танытты. "Хәрби темага багышланган, тынычлык сагында торучы совет кешеләренең хәтәр хәлләрдәге кыюлыкларын, фидакарьлекләрен ышандырырлык реаль тормыш вакыйгалары эчендә тасвирлаган бу әсәр җәмәгатьчелекнең һәм укучыларның уңай бәясенә лаек", — дип яздылар әлеге повесть турында тәнкыйтьчеләр.

Аннан соң ул "Солдат иртә ир була", "Җир җылысы", "Убырут", "Гомернең утлы өлеше", "Лачын кошка күкләр кадерле", "Язмышыңа ышан", "Гыйфрит" кебек әсәрләр иҗат итте. 5 китап чыгарды. Басылмаган "Мәхәббәт сүрәләре" дигән шигырьләр җыентыгы, поэмалары һәм хикәяләре калды. Шигырьләренә көйләр язылды. Башкортостанның танылган артисты Радик Динәхмәтов башкаруындагы "Бүген ярат мине" (Дүртөйле егете Азамат Гыйльманов музыкасы) дигән популяр җырын да үзенә ишетергә насыйп булмады.

Газиз Кашаповны районташлары, авылдашлары да тирән хөрмәт итә иде. Бу мәрхүмне җирләгән вакытта ачык чагылды. Яңа Үзи авылы кешеләре матәм митингы вакытында язучы һәм шагыйрьнең музей-йортын булдыру һәм үзенә һәйкәл-бюст кую турында да карар кабул иттеләр. Бу тәкъдимнәр шунда ук халык депутатларының Аксубай район Советы тарафыннан хупланды. Һәм тиз арада бюст та куелды, музей да ачылды. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Чөнки Г. Кашапов туган халкының язмышы өчен җан атып йөрде. Идел-Йорт, Аксубай яклары мохитенең мәсхәрә ителүенә түзеп тора алмады.

Газиз Кашапов үзе теләгән, 1991 елның 21 февралендә язылган васыятенең 10 нчы пунктында әйтелгән урынга җирләнде. Аның: "Мине, мөмкин булса, туган авылым Яңа Үзигә алып кайтып, Югары як зиратында, әбием, туганнан-туган абыем Афзал янынарак күмәрсез. Теләгем шул. Инде андый мөмкинлек булмаса, теләгәнчә эшләрсез..."

Әйе, авыр булды Газизҗанны озату. Җитмәсә, гүр иясе булып дүрт тәүлек үткәннән соң, Казан телевидениесе "Шигърият" программасында Г. Кашаповның язмасын бирде. Моны мәрхүм үзе генә күрә алмады. Бу тапшыруны, исән чактагы Газизнең үзен гаиләсе, туганнары, дуслары, авылдашлары үксе-үксе карадылар.

**Тәлгать НӘҖМИЕВ.**

# Вөждан — зур сүз...

Заманыбыз — күнеккән шаблоннардан-калыплардан котылу заманы. Узган ел гына арабыздан киткән Газиз Кашапов истәлегенә багышланган бу язмам шуның мисалы булсын иде. Үз гомеремдә байтак юбилей мәкаләсе, үземнән өлкәннәр, замандашлар һәм яшьләрнең туган көннәренә багышланган, яңа чыккан китапларын мактаган мәкаләләр, авторларының үзләре үтенүе буенча китапларына сүз башлары яздым, дистәләгән кешене Язучылар Союзына тәкъдим итеп рекомендацияләр биргәнмен (архивымны актарганда гаҗәпкә калып утырдым — кайберләре Союзга керүгә язудан туктаганнар, бу гөнаһлар минем өстә), нәшрияттагы кульязмаларына уңай эчке рецензия юллаганмын. Гаҗәп, мин матбугатта китапларын мактап чыккан, яки китапларына үзләре үтенүе буенча сүз башы язган иптәшләрнең бик күбесе ахырдан миңа дошман булды. Әллә алар минем турыда ялгыш фикердә булганнар, әллә мин ялгышканмын, Ходай белсен...

Әсәрләренә мин фатыйха биргән, Язучылар Союзына керергә рекомендация язган һәм китабына сүз башы юллаган Газиз Кашапов шулар арасыннан, миңа карата чиста күңелле бердәнбер егет булып калды. Аның белән узган ел июль ахырларында Кама буеның Боровецк урманында ял базасында очраштык: ул минем үтенечем буенча Чаллы кибетләреннән кайбер китаплар алгалый һәм кеше аркылы җибәрә иде. Мин шунда аның белән акча исәбен өздем. Ул ике якка ыргылган куе мыекларына елмаеп:

— Ашыгыч түгел бит, сез — юлдагы кеше, акча кирәк булыр, — дип икеләнеп торды.

— Юк, дөньяныкы дөньялыкта өзелә торсын, — дидем мин, үз гомерем турында уйлап.

Дүрт атналап узгач, төнгә таба, миңа Чаллыдан телефон булды:

— Газиз үлде, иртәгә Аксубайга алып китәбез, — диде хатыны Фәһимә ханым. Мин тынып калдым, аңладым: тиз генә җыенып чыгып чаба торган ара түгел иде. Бердәнбер гамәлем шул булды: Саба район газетасы редакторы, Газизнең университет буенча ахирәт дусты Тәлгать Нәҗмиевкә чылтыраттым. Тәлгать ерак юлга чыгарга машинасын әзерләп йөри икән инде.

Кама буендагы очрашу шулай безнең иң соңгы күрешүебез, якты да, авыр да хатирә булып йөрәктә уелып калды...

Газизнең 1989 елда Казанда басылып чыккан китабы кибетләрдә инде юк. Авторның үтенече буенча мин аңа сүз башы язган идем. Нәшрият хезмәткәрләре ни өчендер аны китап ахырына күчергәннәр. Мондый алымны мин яратмыйм: башка ботинка киеп, аякка эшләпә киеп йөргән кебек тоела ул миңа. Ул сүз башында мин Газизнең тормыш юлында, дөресрәге, тормышының бер борылышында нинди кешеләр белән очрашуы турында язган идем. Кайбер өстәмәләр белән кабатлыйм, чөнки беләм: газета укучыларының барысының да өендә әлеге китап ятмый. Кабатлануым — шуннан.

...1972 елның июлендә мин гаиләм белән Күктүбә (Кырым) иҗат йортында ял итә идем. Шунда Чиләбедән килгән тыйнак егет Рөстәм Вәлиев белән дуслаштык. Ул — язучы, татар тормышын рус телендә тасвирлаучы прозаик. Дуслаштык, ахырдан языша, бер-беребезгә китаплар җибәрә башладык. Бервакыт Рөстәм үтенеч белән хат яза: "Капитан Газиз Кашапов дигән егет аварияга очраган, "комиссовать" иткәннәр. Аның укырга керәсе килә. Казан университетының татар бүлегенә. Син шунда эшлисең бит, ярдәм ит. Юньле егет, үкенмәссез". Шундук яшь офицерга ярдәм итәсем килү хисе биләп алды. Ләкин бу җәйдә мин кабул итү имтиханнарында эшләмим бит. Тиздән ялга китәм, капитан Кашаповка кем күз-колак булыр? Андый кешегә ярдәм итү һич тә начарлык түгел, имтиханнар вакытында нинди генә хәлләр, нинди генә гаделсезлекләр булып бетми! Әмма, Казан университеты ректоры Михаил Тихонович Нужинның (урыны

оҗмахта булсын!) бик тә кешелекле бер сыйфатын белмим түгел: абитуриентлар арасыннан беренче чиратта физик кимчелекләре булган, язмыш тарафыннан каһәрләнгән, җәбер-золым күргәннәрне сайлап алып, кабул итүчеләр исемлегенә башта шуларны кертә иде ул. М. Т. Нужин ректор булып эшләгәндә аудиторияләрдә дөм сукырлар, коляска белән йөрүчеләр, ата-аналары күтәреп аудиториядән-аудиториягә йөртә торган гарипләр еш очрый иде. (Ни гаҗәп, әллә гарипләр бетте — университетта андыйлар юк хәзер, әллә — башка сәбәпләр, мөнәсәбәтләр?) Нишләргә? Рөстәмнең үтенече — минем өчен закон. Һәм мин кабул итү комиссиясендә безнең бүлектән кемнәр эшләвен ачыкладым. Арадан берсе — кешеләргә байтак игелек эшләп тә, шулардан ук шактый зыян күреп яшәп яткан доцент Флера Сафиуллина икән. Кыйссаны шуңа аңлатып бирдем. Газиз Кашаповның имтиханнарда ничек баруын ул контроль астына алган. Ахырдан миңа әйтте:

— Бу мишәр егете бик уңган кешегә ошый, безнең ярдәмнән башка да узган булыр иде ул, — диде.

Университетта Газиз үзен шәп тотты: группаның "костягы" иде алар Тәлгать Нәҗмиев белән (анысы — староста). Группадагы кызлар, ханымнар авыр мәсьәлә килеп чыкканда (имтихан срогын күчерү, лекцияләрне берәр көнгә авыштырып Сабантуйга кайтып килү, берәр имтиханны "досрочно" бирү, фәлән кызның политэкономиядән яки КПСС тарихыннан алган "неуд"ын бетерү һ. б. һ. б.) һәрвакыт Газиз белән Тәлгатькә мөрәҗәгать итәләр иде. Аларның бу дуслыгы Газизнең соңгы көннәренә кадәр барды. Тәлгать Нәҗмиев миңа сөйләде: тормышының иң кыен минутларында *(язучы кеше беркайчан да тулы бәхетле була алмый)* Газиз һич тә хәбәр итмәстән, Сабага килеп чыккалаган, дустыннан киңәш сораган.

Миндә Газизнең алты-җиде хаты саклана. "Мөхәммәт абый, лаеклы дип тапсагыз, шәкертегез генә түгел, язучылыкка да сездән "добро" алу минем өчен бик олы бәхет булыр иде", — дип язган ул бер хатында *(16.02.80)*. Ә минем рекомендация шундук — 8 мартта язылган. 82 нче елда Чаллыга барырга җыенганмын икән, Газиздән хат: "Телеграммагызны көтәм. Теләсәгез, үземдә тора аласыз, чөнки мин июнь ахырынача буйдакмын" *(31.5.82)*. Монысы инде — Фәһимә балалар белән әнисе янына ялга китә дигән сүз.

Гаилә "секрет"ы: Газиз мәрхүм, хатыны Фәһимәнең әнисе, үләннәр белән дәвалаучы өлкән яшьтәге тәҗрибәле карчык турында сокланып сәгатьләр буе сөйли иде:

— Казаннан зур-зур кешеләр килеп дәвалана, бер дәваланган кеше һәр җәйне килә, — дип сөйли иде ул.

"Үтенечемне онытмавыгыз өчен тагын ни әйтим, Мөхәммәт абый? Рәхмәтнең дә иң олысы инде. Энегез кебек күреп, теләсә нинди эштә миңа таяна аласыз. Хәлемнән килгәннең барысын да үтәрмен. Монда әлегә үзгәреш юк. Менә берсекөнгә Мәскәүләр килергә тиеш. Шулар кайгысы белән йөрибез. Зур эш инде ул *(ул вакытта, күрәсең, Газиз Чаллы язучылар бүлегенең җитәкчесе булгандыр: мәскәүлеләр ул заманда шулай провинциягә чыгып тостлар әйтеп рәхәт чигеп йөриләр, әдәбиятны шулай "үстерәләр" иде — М.М.)*. Гаилә туплана башлады. Хатын пыр туздырды: ипиең генә дә булмагач, ничек кунак иттең, гомергә бер бусагаңнан кергән шундый кешене, дип. Мин инде: "Соңгы килүе булмас әле, Мөхәммәт абый — үзебезнеке", — дидем" *(22.06.82)*.

1983 елда язган хатыннан: "М. Галиевне Мәскәүгә укырга китә икән, дип ишеттем. Минем дә андый теләк бар, әмма безне бит әле Мәскәү расламаган (Язучылар Союзына керүен әйтә — М. М.), кәгазьләр дә китмәгән булса кирәк. Мин хыялланып карарга яратам. Шундый бер чакны: "Казан утлары"на Марсель урынына алмаслармы икән, Казанга күчәр идем, дигән нәрсә ялтырап үтте. Сез моңа ни диярсез икән?" *(1.02.83)*.

Гомеренең соңгы елларында Газиз еш кына йә Кара диңгез буена, йә Малеевкага барып йөрде, шунда иҗат итте. Иҗат йортында вакытта ул бик актив эшләде (мәрхүм, алкогольне авызына да алмый иде). Күктүбәдән язган хатыннан өзек: "Бакчасарайга, Иске Кырымга, Севастопольгә барып сәяхәтләр кылып кайттым. Болары да кирәк иде.

Монда, һәр адымда, безнең халыкка бүтәнчә әйтү, Казан-мазан дип бүлү юк, барысы да бер калыптан бара, фикер әйбәт түгел. Шуңа күрә, берничә тапкыр әйткәләшергә, кәеф бозарга туры килде. Инде хатын белән Мәскәүгә хәтле кайтам да, аны озатып җибәргәчтен, Малеевкага сыпыртам. Анда унбиш-егерме көн эшләп кайтам, Алла боерган булса.

Казан һәрвакыттагыча гөрлидер инде ул. Анда көрәш бара, анда яңа китаплар чыгадыр инде. Инде, бу эштән арынсам *(Газиз бу вакытта Чаллы язучылар бүлегенең җитәкчесе иде — М.М.)* мин дә Казанга күчү турында ныгытып уйлармын, ахырысы. Ихтирам белән, өр-яңа иҗат уңышлары һәм сәламәтлек теләп, шәкертеңез Газиз Кашапов" *(11.11.88)*.

Әйе, бу хаттан соң без очраштык. Газиз борчылып сөйләде: Бахчасарай музеенда экскурсовод апайлар татар халкы турында бик кабәхәт нәрсәләр сөйли. Моны тыңлап чыккач, һичшиксез, бер-ике көн авырыйсың. Әнә хәзер Ельцин белән Кравчук диңгез буендагы кыяга басып кочаклашып торалар, ләкин икесенең берсе дә татар халкы өстенә ягылган ялган атны юкка чыгарырга җыенмый. Кырым язмышын бит Кырым татарлары түгел, рус белән украинец хәл итә. Кырым татарын ник икесенең берсе телгә алсын!

Бу елларда Газиз үзенең якташы Хәсән ага Туфан турында роман яза башлаган иде инде. Г. Ибраһимовның тууына 100 еллыкны билгеләү тантанасына Башкортостанга без дүртәү бардык: Әмирхан ага, Туфан Миңнуллин, Газиз һәм мин. Ак төннәр вакыты иде, Авыргазы район үзәгенең иң зур уңайлыгы кран суы һәм раковинасы булган "люкс"та без Газиз белән кояш чыкканчы сөйләшеп яттык. Ул язылачак романының планын сөйләде. Авыргазы Сабантуен карагач алар Туфан белән ерак сәфәргә — мәшһүр каторжан Хәсән аганың сөргендә булган җирләренә чыгып киттеләр. Бу романын язганда аның миңа үтенече төште. "Үтенечем шул: Хәсән ага Туфанның "җидегәнче"ләрне тар-мар китергән мәкаләләре белән таныштыра алмассыңмы? Хәзер инде мин бу хәлләремдә *(Газиз инде бик еш авырый иде — М.М.)* китапханәләргә барып, аларны берәмтекләп, хәрефләп укып җыя алмам. Миңа ул чорның дөреслеге бик кирәк иде. Ярдәм ит, зинһар, яме" *(12.04.90)*.

Ярдәм итә алмадым кебек. Тормышта әллә нинди фаталь, котылгысыз язмышлар була. "Җидегәнче"лек — татар әдәбиятындагы уйдырма, пычрак эш. Фаҗигале тарих. Монда бик күп кеше нахакка рәнҗетелә. Күп кеше адаша, ялгыша, пычрана. Моны, бу тарихны өйрәнү эше дә шулайрак булды. Мәгълүм булганча, "җидегәнчелек" процессында иң кабәхәт рольне күсәк-тәнкыйтьче Ф. Мөсәгыйть уйный. 89 нчы елдамы икән, "Вечерняя Казань" газетасында бу шәхесне тискәре яктан искә алган бер авторны һәм газетаны Ф. Мөсәгыйть судка бирде. Шул чакта газета хезмәткәре һәм автор ярдәм сорап миңа мөрәҗәгать иттеләр. Бер атна буе картотекамны актарып, мин Ф. Мөсәгыйтьнең йөзен ача торган мәкалә язып бирдем. Монда 20—30 еллардагы гарәп графикалы газета-журналларда басылган Ф. Мөсәгыйть мәкаләләре иде. Әмма мәкаләмне редакциядән әлеге автор алып киткән һәм үз табышы итеп судта чыгыш ясаган. Судның магнитофон язмасын тыңладым, ахырдан авторның бу турыдагы мәкаләсен укыдым: барысы да аның табышы булып чыкты. Мин моңа шулкадәр рәнҗедем, ихтимал, шул кәефсезлегем аркасында Газизгә дә материал бирмәгәнмендер.

"Җидегәнчелек"нең тарихын өйрәнү дә кешеләрне буяды.

Ләкин Газиз бик чиста күңелле егет иде. Чиста күңеллелек — язучы өчен иң кирәкле сыйфат. "Вөҗдан" дигән төшенчәне Газиз бик зурдан бәяли иде һәм ул үзенең кыска гомерен вөҗданын бик нык саклаган көе узды. Шуңадыр инде, үзе исән чакта дөнья күргән китабына исемне дә ул "Вөҗдан хәтере" дип куйды.

**Мөхәммәт МӘҺДИЕВ.**
*Июль, 1992.*